Ишелмәсә ярар иде

Әмәт бистәсенең Маршал урамы. Кара-каршы торган ике катлы агач йортларда кеше яшидер дип уйламыйсың да. За йортының бер чаты янгыннан соң күмерләнеп калган, түбәсенең яртысы каерылган, торакның бер өлешенә калайлардан «ямау» салганнар, фатирларга уза торган җылылык торбалары чүпрәкләр белән кат-кат уратылган. Йортлар инде 2009 елда ук авария хәлендә дип табылган; йортта яшәүчеләр башка торакларга күчерелергә тиеш булган. Алар һаман көтә...

5 БИТ

Әй башым...

Башы авыртмаган кеше бармы икән? 90 процент кеше, үз гомерендә бер тапкыр булса да, баш авыртуыннан интегә. Медицина фәннәре кандидаты, Татарстанның Төбәкара клиник-диагностика үзәгенең неврология бүлеге мөдире Марат Сайхунов – баш авыртуының сәбәпләре, аны дәвалау ысуллары турында.

10 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 27.04.2017 | № 45 (5807)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«ТӨП БУРЫЧЫБЫЗ – СОЛДАТНЫҢ ИСЕМЕН КАЙТАРУ»

Дамир Галиев – Казан федераль университетының халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгыш телләр институтының IV курс студенты. Соңгы берничә ел дәвамында ул бер төркем иптәшләре белән бергә Бөек Ватан сугышы кырларында эзләү эшләре алып бара. Без аның белән эзләү нәтиҗәләре турында сөйләштек.

6 БИТ

Реклама

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга – 69 сум 31 тиен
3 айга – 207 сум 93 тиен
6 айга – 415 сум 86 тиен

Ташламалы бәядән язып!

11-21 май, 2017

Абунәче декадасы

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

142 сум 38 тиен – 1 айга
427 сум 14 тиен – 3 айга
854 сум 28 тиен – 6 айга

РЕСПУБЛИКАДА

БАУЛЫ

«Өмет» мәчете ишегалдында җеназаханә төзи башлаганнар. Ул Баулы халкы ярдәме белән салына. Җеназаханә иң авыр вакытларда кешеләргә азрак кына булса да җиңеллек китерү өчен төзелә. Монда мәет шәригать кануннарына туры китереп юыла, дөрес итеп кәфенләнәчәк. Үлгән кешенең якыннарына вәгазьләр аша психологик ярдәм дә күрсәтеләчәк. Авыл халкы, өмә ясап, төзелешкә еш кына үз өлешен кертә. Быел җеназаханәне салып бетерергә ниятлиләр.

БӨГЕЛМӘ

«Бөгелмәдә «Кыстыбый-шоу» фестиваль-конкурсы узган. Бәйгенең беренче этабында катнашучылар район газетасы «Бөгелмә авазы»на кыстыбый рецептлары юллаган. Икенче этапта җиңүчеләрне билгеләгәннәр. Чара кыстыбый турында кызыклы фактлар туплауга, оригиналь рецептларны өйрәнергә мөмкинлек биргән. Баксаң, кайберәүләр кыстыбыйны карабодай белән гөмбә яисә йомыркага суган кушып салынган эчлек белән дә ясыйлар икән. «Кыстыбый-шоу»да беренчелекне «Энҗекәй» балалар бакчасы яулаган.

ЛАЕШ

Саранск шәһәрендә күрмәүче спортчылар арасында Россия беренчелегенә дзюдо ярышлары узган. Анда Лаеш балалар йортында тәрбияләнүче Арианна Литовченко бронза медаль яулап кайткан. Ярышта барлыгы 19 төбәктән 60 спортчы катнашкан. Җиңүчеләр 9 октябрьдә Италиядә узачак Европа парауеннарында катнашачак.

ЮТАЗЫ

Ютазы районы халкы «Җылы аяклар» акциясе кысаларында бер ел дәвамында 400 пар пинетка бәйләгән. Оекбашлар ятим балаларга тапшырылачак.

ЯШЕЛ ҮЗӘН

Яшел Үзәннең 17нче балалар бакчасында оныклары белән бергә әби-бабайларны да юл йөрү кагыйдәләренә өйрәткәннәр. Бу чара интеллектуаль уен формасында узган. Уенда катнашучыларга экранда чыккан видеосорауларга җавап бирергә, катлаулы юл ситуациясендә нишләргә кирәклеген аңлатырга туры килгән. Уенчыларга дипломнар һәм яктылык биреп торган браслетлар тапшырылган.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды

Хәләл ул – кунакчыллык та

vk.com

Соңгы елларда хәләл ризык куллану киң тарала бара. Ул мөселманнарда гына түгел, башка дин тотучылар арасында да популяр. Хәләл ашамлык җитештерү өлкәсендә дә зур үсеш күзәтелә, чөнки кулланучылар базары көннән-көн үсә бара һәм үзенә җәлеп итә. Россиянең мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов сүзләренчә, сәламәт яшәү рәвеше алып баручылар да хәләл туклану белән кызыксына. Хәләл меню тәкъдим иткән кафе-рестораннарның саны да арта.

– Хәтта билгеле ресторатор Аркадий Новиковның рестораннарында да хәләл меню бар. Nestle, McDonald`s кебек эре компанияләр дә мөселманнар өчен хәләл продукция тәкъдим итә. Узган елны «Аэрофлот» самолетларында да хәләл ризыклар тәкъдим ителә башлады. Быел «Ютэйр» авиакомпаниясе белән дә килешү төзелде. Россия тимер юллары акционерлык җәмгыяте белән дә сөйләшүләр алып барыла, – дип сөйләде ул «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында булган матбугат очрашуында.

«ИТЛЕ» проектына нигез салган Руслан Хәйретдинов та аның сүзләрен хуплый.

– Хәләл ул – бисмилла әйтеп суелган ит кенә түгел, сыйфат гарантиясе дә. Безнең продукцияне мөселман кешеләре генә түгел, спортчылар, бала үстерүче әтиәниләр дә, студентлар да ала. Иң башта без хәләл ит, ярымфабрикатлар сата торган кибет кенә ачкан идек. Хәләл ризыкка ихтыяҗ булуын күргәч, киңәергә булдык. Бу – Татарстанда гына түгел, бөтен ил, дөнья буенча да шулай. Россиядә хәләл базары ел саен 30-40 процентка үсә. Җир йөзендә һәр өченче кеше ислам динен тота, аларның саны артып торуын да ассызыклап үтәргә кирәк, – ди ул.

«Түбәтәй» хәләл челтәренә нигез салган Солтан Сафин исә хәләл брендын ризык белән генә түгел, кунакчыллык, югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтү белән дә бәйләп карый.

– Хәләл брендының аспектлары күп аның, шуңа да чималга гына түгел, аны тәкъдим итә белүгә дә басым ясыйбыз, – ди татар ашларын пропагандалаучы.

«Halal Guide» проектын эшләтеп җибәргән Айрат Касыймов сүзләренчә, хәләл ризыкның популяр булуы аның экопродукт булуында да.

– Моңа бигрәк тә чит илләрдә зур игътибар бирелә, әйтик, Малайзиядә McDonald`s компаниясенең 50 процентында хәләл меню каралган. Россия буйлап безнең «Хәләл-гид» кушымтасына көненә 20 нокта өстәлеп тора, – ди ул.

Спикерларның әйтүенә караганда, хәләл ризык җитештерү ул – күпкә катлаулы эш.

– Чимал 20-30 процентка кыйбатрак, безнең өчпочмакларның үз бәясе генә дә 35 сум тора. Итне теләсә кемнән сатып алмыйбыз, ышанычлы фермерларга заказ бирәбез. Көндәшлек тә көчле. Тиздән без кыстыбыйларны төрле эчлек белән чыгарырга уйлап торабыз. Кыстыбургерыбыз да булачак, – ди Солтан Сафин.

Хәләл туклану популярлашкан саен, моның белән акча эшләүчеләрнең саны да арта. Айдар Шаһимәрданов сүзләренчә, кафе-рестораннарда хәләл ризык өчен аерым савыт-саба тотылмый. Бу исә ислам дине кануннарына туры килми, – ди ул.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Шәһәр кәефе

РАФЫЙК ШӘРӘФИЕВ,
пенсионер:

– Казанга ике көннең берендә килеп китәм. Балтач районының Карадуган авылында яшим. Җәмәгать транспортында тукталышлар өч телдә яхшы гына игълан ителә иде, соңгы вакытта автобусларда тынлык. Тукталышлар әйтелмәгәч, башка шәһәрләрдән һәм авыллардан килгән кешеләргә кыен лабаса. Җәйге туристлык чорына мондый кимчелек белән кермәсәк иде. Карадуган читендәге үзәнлеккә агачлар утыртам, шуларның үсүенә куанам.

ГҮЗӘЛ НИЗАМИЕВА,
хезмәткәр:

– Тумышым белән Байлар Сабасыннан мин. Сания белән Хәят әбиләрем икесе дә аш-су осталары иде. Татар милли ризыкларын пешерергә өйрәткәннәре өчен рәхмәт аларга! Ирем Эмиль белән мәш килеп кечкенә улыбызны үстерәбез. Бала тәрбияләү турында китаплар укыйм, башка яшь аналар да укысыннар. Эшкә чыктым, коллектив сагындырды. Казанда күпчелек кеше минем кебек үк ашыга-йөгерә.

ЛЮБОВЬ ГОРБУНОВА,
пенсионер:

– Казанның Жуковский урамында тәгәрәшеп уйнап үстек. Татарстандагы милләтара, динара дуслыкка сөенәм. Казанда яшәвем белән горурланам. Шәһәребезнең Чистай урамын «проспект» дип үзгәртергә кирәк, минемчә. Европа шәһәрләре дәрәҗәсендәге матур һәм төзек урам ул хәзер. Аэропорттан килгән чакта Павлюхин урамындагы йортлар Казанны провинциаль шәһәр кебек күрсәтә.

НАТАЛИЯ ЧУМАНОВА,
маркетолог:

– Әлки районындагы Салман авылыннан мин. Казанда яши башлаганыма – җиде ел. Әле шушы арада гына Сургут белән Чиләбедә булып кайттым. Кызганыч, ул шәһәрләр шактый бетәшкән. Чиләбе урамнары чүпле. Чагыштырып карагач, Казан чын мәгънәсендә Европа дәрәҗәсендә. Шәһәребез урамнарын чүпләмик, кунаклар һәм туристлар сокланырлык булсын. Бию түгәрәгенә йөрим, биергә яратам. Куба республикасына барып кайтырга хыялланам.

РӘМЗИС ТАҖЕТДИНОВ,
пенсионер:

– Казанда кызларымда тора башлавыма – бер ай. Моңа кадәр Сарманда яшәдем. Олыгая барган саен, сәламәтлек какшый шул. Күп еллар машина йөртүче булып эшләдем. Авыл кешесе булу галәмәтедер инде, Казанның дәбердәп-гөжләп торуы җаныма ятмый. Гел яшәсәң, ияләшәсеңдер инде, мин ияләшә алмам шикелле. Урамда транспорт чараларын идарә итүчеләр бер-берсенә дә, җәяүлеләргә дә артык игътибар күрсәтмиләр.

Каен суы эчәр чак

Апрель җиттеме, күпләр каен суын җыя башлый. Кемдер аны файдалы үзлекләре өчен үз итсә, сәламәтлеген ныгытса, икенче берәүләр акча эшләп калырга ашыга. Бу араларда каен суын китереп бирергә теләүчеләрнең игъланнары белән интернет тулган. «Авито. ру» сайты аша без дә берәүгә шалтыраттык.

– Мин каен суын бары тик экологик яктан чиста, трассадан ерак урнашкан урманнан гына җыям. Тиздән каен суы бетә инде. Тагын дүрт көнләп вакыт калды. Агач яфрак яргач, су килми башлый, – ди Лаеш районыннан Руслан.

Бер тәүлеккә 10 литрлап су җыя икән ул. Каен суының литрын 100 сумнан сата. «Сораучылар күп, җыелган суның әрәм булганы юк», – ди. Руслан бу бизнес белән өченче елын шөгыльләнә. Остарганы күренеп тора.

– Каен составында кан басымын көйли торган натрий һәм хлормагний, сөякләр һәм тешләр өчен кирәк булган кальций, нерв системасы һәм мускуллар эшчәнлеген тәэмин итә торган калий витаминнары бар. Бу сок иммунитетны күтәрү өчен дә файдалы, тик бөердә ташлар булганда, табиб белән киңәшләшеп эчәргә кирәк, – диде ул безгә.

Илдус Мөхәммәтшин, 45 ел тәҗрибәсе булган урманчы, Мамадыш:

– 1975-90 елларда Мамадыш урман хуҗалыгында үзебез дә сезонына 60 тоннага якын каен суы әзерләдек. Аны Тәкәнеш авылындагы заводка илтеп тапшыра идек. Күпләп каен суын җыючылар өчен урман хуҗалыгыннан рөхсәт кирәк. Агачларга зыян салган өчен, закон нигезендә, гражданнарга – 3-4 мең сум, юридик затларга 200-300 мең сум штраф каралган. Бер каеннан икеөч ел рәттән су алырга ярамый. Ул бит каенның каны кебек. Зыян килгән агач корый башлый. Тишкән урынны сумала яисә балчык белән сылап калдырырга кирәк.

ТОП – 3

КАЗАННАН Пекинга беренче тапкыр туры авиарейслар оча башлаячак, дип хәбәр итте Казан аэропорты матбугат хезмәте җитәкчесе Адел Гатауллин. Рейс июньнән октябрьгә кадәр булачак. Әлегә расписание төгәл билгеләнмәгән.

ТАТАРСТАН Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында һәм «Татарстан Республикасы хезмәтләре» мобиль кушымтасында хәзер газ өчен комиссиясез түләргә мөмкин. Бу Татарстан Дәүләт хезмәтләре порталыннан файдаланучыларга җайлы булсын өчен эшләнгән. Соңгы елларда коммуналь хезмәтләргә электрон формада түләүчеләр саны арта бара. 2016 елда гына да дәүләт хезмәте порталы аша 512 миллион сумлык 821 мең түләү башкарылган, дип хәбәр итә Татарстан Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы матбугат хезмәте.

25 АПРЕЛЬДӘН 15 майга кадәр Татарстанда янгынга каршы махсус режим кертелә.

Бу вакытта коры үләнне һәм чүпләрне яндыру, учакта шашлык, башка ризыклар пешерү, урман участокларына якын бакчаларда, балаларны сәламәтләндерү лагерьларында, икътисади объектларда, сәламәтләндерү оешмаларында, урман-парк зоналарында пиротехник эшләнмәләр куллану тыела.

КҮРШЕЛӘРДӘ

Чувашиядә реклама элмә такталарын куюны чикләргә булганнар. Чабаксар шәһәре депутатлары шәһәрнең тышкы төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр керткән. Хәзер тимер юл аркылы чыгу урыннарында, тоннельдән чыгу юлларында, тротуарларда реклама урнаштыру тыела. Шулай ук янып торган элмә такталарга карата да чикләүләр бар. Аларның яктылыгы кеше тәрәзәсенә туры төшәргә, яшәүчеләргә комачауларга тиеш түгел.

* * *

Мари Элдан Казанга 5 майдан поездлар йөри башлаячак, дип хәбәр итә «Мари Медиа» агентлыгы. Ике республика арасын 3 сәгатьтән артыграк узарга туры киләчәк. Җомга, шимбә, якшәмбе көннәрендә Йошкар-Олага поездлар Казаннан сәгать 15.10, 18.50дә кузгалачак. Тулырак расписаниене тимер юл вокзалы кассаларыннан белергә була.

* * *

Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә 15 йортның ишегалды су астында калган. Кинәт кар эрү, яңгырлар аркасында Белая елгасының суы күтәрелеп, шундый нәтиҗәләргә китергән. Башкортстанның Гадәттән тыш хәлләр идарәсе, зур зыян күрүчеләр юк, дип белдерә. Шулай да халык белән кабат кисәтү эшләре уздырганнар. Өч көнгә җитәрлек су, ризык әзерләргә, документларны пакетларда сакларга, елгалардагы суның артуын күзәтеп барырга кирәклеген искәрткәннәр

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Тукай бүләге ияләре

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кичә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында узган чарада 2017 елда Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреатларын котлады. Быел Тукай бүләгенә 19 кеше тәкъдим ителгән иде. «Арыш тәме» китабы өчен язучы Мәдинә Маликова, Татарстанның милли мәдәни мирасы турындагы «Мәңгелек гөлчәчәкләре: татар һәм рус телендәге мәкаләләр җыелмасы» өчен рәссам Розалина Шаһиева Тукай премиясе белән бүләкләнде. Тарихта беренче тапкыр дин әһеле, «Хәтер» мәчете имам хатибы Харис Салихов та «Александр Пушкин, Габдулла Тукай иҗатында дөньяви һәм дини мотивлар һәм бүгенге көндә әхлакый тәрбия бирү проблемалары» эше өчен Тукай премиясен алды.

Минтимер Шәймиев – Россиянең Хезмәт Герое

Россия Президенты Владимир Путин Указы белән, «Яңарыш» тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фондының попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиевкә Россиянең Хезмәт Герое исеме бирелде, дип хәбәр итә Кремль сайты. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бу вакыйга уңаеннан Дәүләт Киңәшчесен котлады. «Сез Татарстанны яңа кимәлдәге үсеш мәйданына алып чыктыгыз, куелган максатларга ирешү өчен, булган мөмкинлекләрне һәм нәтиҗәле тырышлыкны берләштереп туплый алдыгыз, туган Татарстаныбызда да, шулай ук Россиядә дә хаклы рәвештә көчле сәясәтче, алдан күрүчән дәүләт эшлеклесе һәм талантлы җитәкче буларак, какшамас абруй казандыгыз», – дип теләкләрен җиткерде Президент.

Сүз уңаеннан, 2013 елдан бирле әлеге исем һәр елны биш кешегә генә бирелә. Минтимер Шәймиев – Владимир Путин бүләкләгән 25 Хезмәт Герое арасында татарлардан – икенче һәм төбәк җитәкчеләре арасында – беренче.

Фатыйх СИБАГАТУЛЛИН,
Россия Дәүләт Думасы депутаты:

Ирек мәйданында Шәймиевкә һәйкәл куярга кирәк. Ленин урынында атка атланган Шәймиев торырга тиеш. Кешенең исән чагында кадерен белмиләр, ә вафатыннан соң, һәйкәл куярга кирәк, диләр. Минемчә, кеше исән чакта ук аның хезмәтен бәяләп һәйкәл куярга вакыт. 80 яшьлек юбилеенда ук Шәймиевнең герой икәнен аңладым, чөнки ул безнең иң лаеклысы.

(«Бизнес-онлайн»га биргән әңгәмәсеннән)

Магнит давыллары

Алдагы атнада җирнең магнит кыры чагыштырмача тыныч. Шулай да 27 апрельдә һәм 1 майда артык көчле булмаган магнит давыллары күзәтелә. Йөрәк-кан тамырлары авырулы, кан басымы югары булган кешеләргә үз сәламәтлекләренә игътибарлы булырга киңәш ителә.

Халык ял итәргә теләми?

Үткәрелгән сораштырулар буенча, Россия халкының 50 проценты быел җәй ялга чыгып тормаска булган. Белгечләр, соңгы елларда бу күренеш аеруча еш күзәтелә, ди. Төп сәбәбен илдәге кризис белән бәйләп аңлаталар. Шул ук вакытта акча җиткерә алмаудан гына түгел, кемдер эшен калдырырга кеше тапмаудан, ял итәргә теләге булмаганга җәйге ялдан баш тарткан. Ә сез җәй көне ял итәргә җыенасызмы?

Ирек ШӘРИПОВ, Татарстан халыкларының Дуслык йорты директоры, Дәүләт Советы депутаты:

– Без, гадәттәгечә, елның бер өлешен туган якта эшләп уздырырга, икенче яртысында диңгез буена барырга җыенабыз. Хәзер заманалар үзгәрде, эшеннән бер айга ялга китүчеләр сирәк. Үз эшен җиренә җиткереп башкарган җаваплы кешеләрнең тыныч күңел белән вазифасын озакка калдырып китә алмаулары аңлашыла да. Отпускны өлешләп алу гадәткә керде, иң күбе – ике атнага. Җитәкчеләрдән дә, төп эшегездән тыш нәрсә белән шөгыльләнәсез, дип кызыксынганым бар. 80 проценты: «Бер шөгылем дә юк, бар вакытымны эшкә багышлыйм», – дип җавап бирә.

Азат ФАЗЛЫЕВ, җырчы:

– Быел күп эшләргә туры килде. Киләсе елга концертларыбыз тагын да күбрәк булыр дип көтелә. Чит төбәкләргә дә күбрәк чыгарга җыенабыз. Шуңа да ял итмичә булмас, мөгаен. Дөрес, бер көн өйдә эшсез утырсак, җан түзми башлый инде безнең. Чит илгә баргач та, җиде көннән артык тора алмыйм. Туган як сагындыра. Шулай да быел диңгезгә барып кайтырга исәп. Эштән арынып торырга, башны сафландырырга, яңа энергия тупларга ял кирәк.

Айзилә БАРИЕВА, шәхси оешмада менеджер:

– Мин ел саен ялны документта рәсмиләштереп акчасын алам да эшләвемне дәвам итәм. Болай да атнасына бер көн генә ял каралган. Нык арыйм, әлбәттә. Кайсы көнне эшкә барасым да килми. Тик кредитларымны түләп бетермичә, ял турында уйлый алмам, мөгаен.

Талпаннар уянган

Быел талпаннар гадәттәгедән иртәрәк уянган, дип хәбәр итә Роспотребнадзорның Татарстан идарәсе. Республикада талпан тешләп, биш кеше хастаханәгә мөрәҗәгать итәргә дә өлгергән инде. Аларның икесе – балалар.

Урман бете, гадәттә, тәннең йомшак урынына – култык асты, чәч арасы, колак артына кадала. Кан белән туклапып, үзе йөрткән инфекцияне кешегә күчерә. Талпан энцефалиты сәламәтлек өчен куркыныч тудыра. Кеше урман бете кадаганын еш кына сизми, беренче билгеләре дә атна-ун көннән соң гына, кайчакта хәтта бер айдан соң беленә. Кешенең температурасы күтәрелә, хәлсезлек сизелә, башы авырта, муен, буыннар сызлый. Былтыр Татарстанда өч кеше энцефалит вирусын йоктырган. Урман бетләре катнаш урманнарда үлән арасында ешрак очрый. Аеруча май урталарында күбәя. Роспотребнадзор идарәсе белгечләре урманнарда, ял итү паркларында саграк булырга киңәш итә.

Сүз уңаеннан, Азнакай, Аксубай, Актаныш, Әгерҗе, Зәй, Саба, Теләче, Югары Ослан, Ютазы районнары һәм Казан, Чаллы шәһәрләрендә – республиканың барлыгы 30 җирлегендә талпаннар күбрәк очрый икән.

Роспотребнадзорның Татарстан идарәсендә 1 майдан «кайнар элемтә» эшли башлаячак. Талпан тешләгән очракта, энцефалит вирусы белән бәйле барлык сораулар буенча бәйрәм һәм ял көннәрендә ***8 (843) 238-98-54,*** *башка вакытта* ***238-53-68, 238-21-74*** *номерлары аша шалтыратырга мөмкин.*

ТАЛПАННАН САКЛАНУ ӨЧЕН

- энцефалит вирусыннан саклануның иң ышанычлы ысулы – вакцинация ясату. Ул талпан сезоны башланганчы 1,5-2 ай алдан үткәрелә.
- табигатькә чыкканда, талпаннар сирәк булган җирләрне сайлагыз. Әйтик, каенлыкларда, нарат урманнарында талпаннар бик булмый. Ә менә ачыклыкта, юл буйларында алар күбрәк очрый.
- кешенең киеме тәнен мөмкин кадәр томалап торсын, бөҗәкләрне куркыта торган махсус кремнар кулланырга да була.
- урманнан кайткач, үзеңне җентекләп тикшереп чыгарга кирәк. Талпан тешләгәнне абайласагыз, тиз арада хастаханәгә мөрәҗәгать итегез.

Хакимият кәнәфие – яшьләр кулында

20 яшең дә тулмаган килеш, министр кәнәфиенә утырып буламы? Була икән. Россиянең IX Яшьләр хакимияте ассоциациясе корылтаенда әнә шундый министрлар Казанга җыелды. Алар – илнең яшьләр хакимияте вәкилләре.

Алисә САБИРОВА

Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева сүзен яшьләргә «хезмәттәшләр» дип эндәшеп башлады. Яшьләр сәясәте вәкилләре дә бит төрле ведомство җитәкчеләре, министрлар ярдәмчесе вазифасын үти.

– Без яшьләребез белән горурланабыз. Татарстанда бик күп башлангычлар, иҗтимагый проектлар яшьләр ярдәмендә тормышка ашырыла. Безнең һәрберебез яшьлектән үсеп чыккан. Мин 42 яшемдә булсам да, әле дә 18дә кебек. Хәзер дә миллионлаган инициативаны тормышка ашырырга әзермен. Барысы да дөньяга караштан тора, – диде Ләйлә Фазлыева.

Илнең 60 төбәгеннән килгән 130лап яшь сәясәтче өч көн дәвамында Татарстан хакимияте тәҗрибәсе белән таныша. Элек мондый съездлар 2008 елдан алып бары тик Мәскәүдә генә үткән. Әле узган ел гына, традициясен бозып, Воронеж каласына күчкән. Хәзер исә ул шулай төбәкләр буйлап йөриячәк.

Яшьләр хакимияте олылардан бер дә аерылмый. Биредә эшләүчеләр төрле министрлыкларда тәҗрибә туплый, яшьләргә кагылышлы проектларны тормышка ашырырга ярдәм итә. Татарстан яшьләр хакимияте нибары дүрт ай элек формалашкан. Бирегә «Кадрлар резервы» республика проекты җиңүчеләре генә эләгә ала. Яшьләр хакимияте рәисе вазифасын Дина Гайзатуллина башкара. Хакимияттә 23 кеше, араларында студентлар, укытучылар, эшче яшьләр дә бар.

– Соңгы ике елда безгә 14 яңа субъект кушылды. Татарстан – моның бер мисалы. Эшли башлауларына шул кадәр аз вакыт булып та, безне кабул итә алган өчен республика хакимиятенә рәхмәт сүзләрен җиткерәсем килә. Ассоциация зураюына карамастан, сыйфат ягы аксамый. Хәзер яшьләр хакимиятенең эш дәрәҗәсен арттырырга кирәк, – диде Россиянең Яшьләр хакимияте ассоциация рәисе Сергей Конев.

Ул шулай ук 2016 елда илнең биш иң яхшы яшьләр хакимиятен атап китте. Җиңүчеләр дип Рязань өлкәсе, Саха Республикасы, Красноярск крае, Воронеж өлкәсе, Ямало-Ненец автоном округы табылды. Яшьләр Россия Федерациясе хакимияте каршындагы Финанс университетының политология факультетына ташламалы шартларда укырга керү мөмкинлеге отты.

Аеруча Воронеж яшьләре актив булып чыкты. Бүләк алу өчен, җитәкчеләре Мария Ковалевага дүрт тапкыр залга чыгарга туры килде.

– Без 2009 елда формалаштык. Ике ел саен составыбыз үзгәреп тора, ел саен квалификацияне тикшерәләр. Безнең эшкә килү өчен сайлаулар оештырабыз, яшьләрдән кейслар чиштерәбез, – ди Мария.

Күршеләребез Ульяновск өлкәсе исә рейтинг буенча былтыр 35нче урында гына булса, хәзер иң яхшылар унлыгына күчкән.

– Иң ошаган проектларның берсе «Тормыш бүләк ит» дип атала. Яшьләр аборт ясатырга җыенган аналарны кире күндерә. Юридик һәм консультация ярдәме күрсәтә. Губернатор белән еш очрашабыз. Аралашу рәсми булмаган рухта бара. Шулай ук финанс грамотасы, экология, спорт юнәлешендә дә актив эшлибез, – диде Ульяновск өлкәсе яшьләр хакимияте рәисе Марина Рогаткина.

Корылтайда яшьләр Казанда имән агачлары утыртта. Әлеге аллея Яшьләр хакимияте исемен йөртәчәк. Футбол ярышларында катнашачак, төрле утырышлар, килешүләр дә төзеячәк.

«Үлемсез полк» акциясендә быел Казанда 100 меңгә якын кеше катнашыр дип фаразлана. Анда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның да катнашуы көтелә.

«Үлемсез полк» сафларына кушыл

– Кемдә нинди фоторәсем сакланган, шуның белән чыга. Балалар бабасының рәсемен еш ясый икән, шул рәсемне күтәрсен. Бу – Бөек Җиңү яулаган бабаларыбызга, әтиләребезгә мәңгелек дан һәм хөрмәт белдерү, – диде Татарстан Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева.

«Үлемсез полк» 9 майда 13.00 сәгатьтә Карл Маркс урамында Толстой урамыннан Ирек мәйданына кадәрге арада туплана. Керү – Горький паркы ягыннан. Колонна 15.00 сәгатьтә кузгала. Хәрәкәт башлангач, колоннага Карл Маркс урамына тоташкан урамнардан да кушылып китеп булачак.

Маршрут Карл Маркс – Лобачевский – Кремль урамнары буйлап уза һәм 17.00 сәгатьтә Меңьеллык мәйданында тәмамлана. «Үлемсез полк» акциясе вакытында Карл Маркс урамындагы җәмәгать транспорты Вишневский урамы буенча хәрәкәт итеп торачак. Шулай ук Меңьеллык мәйданында да транспорт хәрәкәте вакытлыча туктатылачак.

– Казанда «Үлемсез полк» юлы ике километрдан артык араны тәшкил итә. Баш киеме кию, җылырак киенү, уңайлы аяк киеме кию, кулчатыр алу кирәк, – дип киңәш итте Ләйлә Фазлыева.

Дамир БӘДРИЕВ.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Ишелмәсә ярар иде

Әмәт бистәсенең Маршал урамы. Кара-каршы торган ике катлы агач йортларда кеше яшидер дип уйламыйсың да. 3а йортының бер чаты янгыннан соң күмерләнеп калган, түбәсенең яртысы каерылган, торакның бер өлешенә калайлардан «ямау» салганнар, фатирларга уза торган җылылык торбалары чүпрәкләр белән кат-кат уратылган. Тәрәзә төбендә һава сулап утыручы авырлы яшь хатынны күреп, гаҗәпләнеп калдык. Баксаң, бу йортта унлап гаилә яши икән.

Эльвира МОЗАФФАР,
Казан, Әмәт бистәсе

ГОМЕР БУЕ КАЙНАР СУ ЮК

Щепоповлар яшәгән фатирга узабыз. Торак хуҗасы Варя йортның кайчан төзелгәнен төгәл генә хәтерләми дә.

– 1950 елларда салынган торак бугай. Гомер буе шушында яшибез инде. Кайнар су күргәнебез юк. Кайбер кешеләрнең бәдрәфләре дә эшләми. Биш еллап безгә яңа фатир вәгъдә итәләр. Күршем, өй туен көтә-көтә, теге дөньяга китеп барды, – ди.

Аш бүлмәсендә аяк басар урын да юк. Кечкенә генә бүлмәдә ашарга да пешерәләр, бер чатта кием-салым өелгән, савыт-саба да шунда. Гөлләр дә үсеп утыра. Дартс уенына кадәр бар.

– Берсендә ашарга пешергәндә, түшәмнән зур гына плитә кисәге өстебезгә ишелеп төште. Әле ярый зыян килмәде, – ди Варя әбинең оныгы.

Ике бүлмәле фатир. Коммуналь хезмәтләр өчен Щепоповлар 6800 сум түли. Су, ут өчен исәпләү җайланмалары искергән дип, гаиләгә коммуналь хезмәтләр фатирда теркәлгән кеше исәбеннән чыгып, аерым тарифлар буенча исәпләнелә. Шуңа да, күрәсең, кайнар су булмаса да, шактый акча түләргә туры килә. Җитмәсә, авария аркасында, салкын көннәрдә ике атна буе җылылык булмаган.

– Ике кат юрган астында кием белән калтыранып яттык. Йортта кечкенә балалар да бар бит. Урамда фатирдагыга караганда җылырак була иде. Кайчанга кадәр шулай тилмербез икән? – дип зар елый Варя апа.

Йорт төрле яклап чатнаган, диварлардагы буяулар купкан, электр чыбыклары асылынып төшкән. Гадәттән тыш хәлләр идарәсеннән, янгын куркынычсызлыгын тикшерүчеләр килеп кисәтү эшләре үткәреп китә икән. Берсендә йорт яна башлаган. Ярый вакытында сүндерә алганнар.

Йорт инде хәтта бер якка авышкан да. Шуның аркасында тәрәзәләр дә кыйшайган, ишекләр дә ябылмый интектерә.

«ОНЫТТЫЛАР БЕЗНЕ»

Каршыдагы нәкъ шундый проект белән салынган 3нче йорт та мактанырлык түгел.

Кечкенә кызлары белән һава суларга чыккан Фәсәховлар:

– Яңа ел алдыннан һәрчак, яңа торакка күченәчәксез, дип вәгъдә итәләр. Документлар җыйдырталар – нәтиҗә генә юк. Хәллерәкләр күченеп китте. Мондагы фатирларын кешегә вакытлыча биреп, акча эшлиләр. Хәзер күршебездә җыен исерек. Куркыта, әлбәттә. Тикшерүче, тәртип урнаштыручы да юк. Оныттылар безне, – диләр.

Казан Башкарма комитетының карары нигезендә (№11567), Маршал урамындагы 3, 3а йортлары 2009 елда ук авария хәлендә дип табылган һәм әлеге торакларны җимерергә дип хәл ителгән; авария хәлендәге йортта яшәүчеләр башка торакларга күчерелергә тиеш булган. Тик үзгәреш кенә юк.

Бу сорау белән Казан шәһәре мэриясенә дә мөрәҗәгать иттек.

– Маршал урамындагы 3, 3а йортларына килсәк, анда яшәүчеләрне фатир белән тәэмин итү максатыннан, аукцион уздырылды. Нәтиҗәдә Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт Торак фонды җиңүче дип танылды. Хәзерге вакытта, аукционда җиңүчедән фатирлар көтәбез. Контракт нигезендә, бу процедура 1 июньгә кадәр төгәлләнергә тиеш. Маршал урамының авария хәлендәге 3, 3а йортларында яшәүчеләрне 1 сентябрьгә кадәр яңа торакларга күчерү ниятләнелә, – дип җавап бирде «ШК»га Казан мэриясе матбугат үзәге хезмәткәре Ринат Ширманов.

Дәүләт Советы матбугат үзәгеннән алынган мәгълүматлар буенча, Татарстанда 2017 елның 1 сентябренә кадәр авария хәлендәге тораклардан 749 кешене яңа фатирларга күчерергә җыеналар. Быел бу максатларда 65 йорт төзелә.

2012-2013 елларда республикада гомуми мәйданы 71,6 мең квадрат метр булган 312 авария хәлендәге күп фатирлы йортларда яшәүчеләрне күчергәннәр иде. Биш меңнән артык кеше яңа тораклы булды. 2015 елда исә «Авария хәлендәге тораклардан күчерү» программасы буенча 10 784 кешегә фатир ачкычлары тапшырылды. Әлеге программаны 2019 елга кадәр озайту фикере яңгыраса да, 11 мартта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кешеләрне яңа торакларга күчерү процессын 2017 елның сентябренә төгәлләргә кушкан. Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин сүзләренчә, авария хәлендәге йортларда яшәүчеләрнең 80 проценттан артыгы белән яңа торакларга күчену турында килешүләр инде төзелгән. Кайберләренең иске фатирларыннан күченәсе килми, бу – программаның тулы көченә башкарылуына каршылыклар тудыра.

Тәкъдим, фикерләрегезне редакциябезгә **8 (843) 562-50-12, 562-50-03** номерлары аша юллый аласыз.

СОРАУ-ҖАВАП

Быел җәйгә поезд белән Кырымга барырга исәпләп торабыз. Анда барып кайткан танышлар бердәм билет алырга киңәш итте. Әлеге билет турында аңлатып язсагыз иде.

Эльмира ГЫЙСМӘТУЛЛИНА,
Казан.

Горький тимер юлларының Казан бүлеге матбугат хезмәте:

– 2017 елгы җәйге сезонга Кырымга бердәм билетлар 30 апрельдән 30 сентябрьгә чаклы сатыла. Бердәм билет буенча Кырымның җиде шәһәренә: Керчь, Симферополь, Севастополь, Феодосия, Судак, Евпатория һәм Ялтага барып була. Бәяләре узган елгы кебек калды. Ул үз эченә автотранспортны һәм диңгез транспортын ала. Шуны истә тотыгыз: бердәм билетка поезд билетының бәясе кермәгән. Поезд белән сез Анапа яки Краснодарга кадәр бара аласыз. Аннан инде бердәм билет белән, башта автобуска, аннары диңгез транспортына, аннан инде тагын автобуска утырып, башка шәһәрләргә барып җитәсез (автобус – паром – автобус).

Анападан Керчька – 380 сум, Симферопольгә – 590 сум, Севастопольгә – 690 сум, Феодосиягә – 460 сум, Судакка – 540 сум, Евпаториягә – 690 сум, Ялтага – 700 сум;

Краснодардан Керчька – 560 сум, Симферопольгә – 710 сум, Севастопольгә – 810 сум, Феодосиягә – 590 сум, Евпаториягә – 810 сум, Ялтага – 820 сум, Судакка – 660 сум.

Биш яшькә кадәрге балалар бердәм билет буенча бушка йөри ала, аларга аерым урын бирелә.

Кырымга бару һәм кире кайту өчен бердәм билетны билет кассаларыннан яки «РЖД» сайтыннан поезд билеты белән бергә алырга була. Анапа яки Краснодарга барып җиткәч тә ала аласыз.

«Төп бурычыбыз – солдатның исемен кайтару»

Дамир Галиев – Казан федераль университетының халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгыш телләр институтының IV курс студенты. Соңгы берничә ел дәвамында ул бер төркем иптәшләре белән бергә Бөек Ватан сугышы кырларында эзләү эшләре алып бара. Яу кырында башларын салган солдатларыбызның җәсадләрен эзләп табып, аларны күтәреп, исемнәрен кайтару буенча гаять дәрәҗәдә җаваплы һәм мактаулы эш башкара әлеге студент отрядлары. Бу эшләр нинди тәртиптә алып барыла? Эзләү барышында татарлар табыламы? Кайчандыр хәбәрсез югалган солдатларны кая җирлиләр? Гомумән, Дамирның шәхси күзаллауларын экспедиция ничек үзгәрткән? Бүгенге әңгәмәдә әнә шушы сорауларга җавап эзләрбез.

ЭЗТАБАР

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Әлеге экспедицияләр сугыш турындагы фикерләремне, аңа булган карашымны тамырдан үзгәртте. Беренче эзләнүләргә барганчы, сугышны шулкадәр коточкыч авыр вакыйга дип кабул итми идем. Әмма сугыш узган кырга беренче тапкыр аяк баскач, кыйпылчыклар эзли торган махсус җайланмабыз адым саен диярлек тавыш бирә башлагач, монда барган вакыйгалар берәм-берәм күз алдымнан узды. Солдатларга коточкыч авыр шартларда дошманга каршы көрәш алып барырга туры килгән. Аларның күбесе безнең яшьтәшләр бит – 19-20 яшьлек егетләр. Үземне шул урынга, шул вакытка куеп карадым да, үз-үземә: «Ә мин нишләр идем икән?» – дигән сорау бирдем. Дөресен әйтәм, җавап таба алмадым. Гомумән, экспедиция һәр кешене күпмедер дәрәҗәдә үзгәртәдер. Сугышта булмаган кеше аның ни икәнен аңламый, диләр. Экспедиция турында да шулай дип әйтергә була. Чыннан да, хәзер: «Мин – эзләүче», – дип горурлана алам. Әйе, моның өчен безгә беркем дә түләми, урманда, палаткаларда яшибез, үзебез ашарга әзерлибез. Әмма миңа менә шунысы кадерле дә. Гадәттә, 9 майны шушы кырларда каршылый идек. Һәм эзләү отрядлары өчен бу чыннан да зур бәйрәм. Менә быел, Казанда эшләрем күп булу сәбәпле, экспедициягә бара алмыйм, шуңа күрә күңелдә ниндидер бер бушлык хөкем сөрә.

– Дамир, эзләү отрядына кушылып китеп, сугыш кырларында барган эзләнүләр белән кызыксынуың кайчан башланган иде соң?

– Ленинград өлкәсенә тәүге экспедициям беренче курста укыганда ук булды. Хәзерге вакытта алты эзләнүдә катнаштым. Шуларның бишесе Ленинград өлкәсенең Любань шәһәре тирәсендә булса, берсе Көнчыгыш Белоруссиядә иде. Гадәттә, отрядның төп составында ун кеше эшли. Экспедицияләр елга ике тапкыр – 15 апрельдән башлап 10 майга кадәр һәм сентябрьдә уза. Көзге экспедицияләрдә гадәттә урынны эзләү, ачыклау һәм тикшерү булса, язын шул территориядә казу эшләре алып барабыз. Бер генә эш тә болай гына эшләнелми. Экспедициягә кузгалыр алдыннан рөхсәт алына, отряд командиры архив материаллары белән зур эш алып бара. Һәм без инде эшләячәк территория турында мәгълүмат туплап, сугыш вакытында биредә нинди вакыйгалар булганын белеп барабыз. Любань экспедициясе үзе, гомумән, 1989 елдан бирле бара. Без эзләнүләр алып бара торган урында нигездә көтеп торучы фронт булган. Соңгы өч экспедициядә дә бер үк урында булып, бер тирәне эшкәрттек.

– Эзләнү эшләре алып барганда, нәрсәләргә тап буласыз?

– Күпчелек очракта тимер-томыр – снарядлар, гранаталар, сугыш кирәк-яраклары (патроннар, гильзалар) табыла. Ә менә һәлак булганнарның җәсадләренә сирәгрәк юлыгабыз. Тәртип буенча, аларны тапкач, археологик ысул белән күтәрәбез. Монда аеруча зур эш эшләнә. Сугышта һәлак булганнарның күбесе күмелмичә, ягъни җир өстендә шул килеш кенә ятып калган. Аннан соң санитарларның сняряд чокырына берничә мәетне бергә күмү очраклары да гадәти күренеш булган. Болары авыррак күтәрелә, чөнки анда ничә кеше күмелгәне билгесез бит. Аларны казып алганда, һәр кешенең сөяген таркатмыйча гына бергә күтәрергә тырышабыз. Соңыннан җәсадләр махсус эксгумация капчыкларына урнаштырылып, пломба куела. Әлбәттә, болар барысы да документ белән расланa, мәгълүматлар базасына кертелә. Аннан соң капчыклардагы җәсадләрне 10 майда тантаналы рәвештә җиргә иңдерәбез. Алар бик зурлап, хөрмәт белән күмелә. Гадәттә, күмү йоласын башкарыр-га поп килә, анда мулла чакыру проблемалы. Мемориал Ленинград өлкәсендәге Тоснен районы, Чудской Бор авылында урнашкан. Анда 4500 рус солдаты күмелгән. Бабайлары, әтиләренең соңгы йорты булган җиргә туганнары да килә.

– Җәсадне күтәргәндә үк аның рус кешесеме, немецмы икәнен билгеләү мөмкин түгелдер?

– Бөтенесен дә йөз процент ышаныч белән әйтә алмыйбыз, әмма күпчелек очракта аның безнекеме, немецмы икәнлеген билгеләп була. Кием калдыклары, мылтыклар, гильзалар, төймәләр ярдәмгә килә. Без үзебез үк скелетның физиологик үзенчәлекләре буенча (баш сөягендәге җөйләрнең ни дәрәҗәдә капланган булуы, тешләр, сөяк зурлыгы буенча) якынча яшен һәм җенесен билгелибез. Аннан соң мондый вакытта безгә скелетта табылган «үлем медальоны» ярдәмгә килә. Ул армиядә 1940 елда кертелгән. «Үлем медальоны» кара пенал эчендәге язмадан гыйбарәт. Анда бөтен мәгълүмат – солдатның исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туган елы, нинди район военкоматыннан чакырылган булуы, әти-әнисенең кем икәнлекләре – барысы да язылган. Солдат һәлак булгач, тәртип буенча, командир пеналны үзенә алган һәм бу турыда туганнарына хәбәр ителгән. Әмма солдатлар арасында: «Әгәр аны тутырсаң, һичшиксез үтерәчәкләр», – дигән ышану булган. Шуңа күрә күбесе бу эшне эшләмәгән. Аннан соң медальонны яхшылап ябып куймаучылар да булган.

Эзләү барышында, бик сирәк очракта, номерлы медальләр яки орденнар да очрый. Болардан кала, һәр солдатның диярлек ниндидер шәхси әйбере табыла. Мәсәлән, кашык, котелок, фляга, теш порошогы. Кашыкка, гадәттә, солдат хезмәт иткән частьның номеры язылган. Безнең бит иң төп бурыч – кешенең сөякләрен табу гына түгел, ә аның исемен кайтару. Һәм әлеге мәгълүматны туганнарына җиткерү. Шуңа күрә җәсаднең кем икәнлеген ачыклар өчен, иң вак детальләргә дә игътибар итәбез.

– Үзең эшләгән дәвердә татарлар табылганы булдымы?

– Татарлар турында әйтә алмыйм, ә менә татарстанлылар шактый табыла. Без 2015 елның язында исемле плитәләр урнаштырган идек. Шундагы мәгълүматлар турында әйтсәк, 600 кешенең исемен таба алдык. Әмма нишләптер алар арасында татар фамилияләрен күргән юк. Шулай да Урта Азия халыкларына туры килгән исемнәр күп очрый. Мөселманнардыр инде алар.

– Шәхсән үзең беренче тапкыр нәрсәгә юлыккан идең?

– Вак-төяк тимер-томыр иде ул. Ә менә шәхсән үземнең кеше җәсадләренә тап булганым юк. Казыганым, күтәргәнем бар. Хәтерлим әле, беренче экспедициядә без хәбәрсез югалган солдатны күтәрдек. Аның шәхси әйберләреннән кашыгы да бар иде. Анда ТФФ дип язылган иде. Миннән еш кына: «Бу эш куркынычмы?» – дип сорыйлар. Юк, беренчесендә үк курыкмадым. Киресенчә, ныграк эзләргә, күбрәк табарга тырышасың. Алда әйткәнемчә, санитар күмүләрне күтәрү авыррак, чөнки анда кешеләр берсе өстенә берсе күмелгән. Без эшли торган территориянең бер өлешендә – зәңгәр балчык. Анда мәетләр яхшы сакланган иде. Шуны ачкач, бөтен җиргә мәет исе таралды. Аны бер дә онытмамдыр, ахры. Бер егетебездә хәтта аллергия башланды. Тагын 2015 елда күтәргән воронка истә калган, анда 15 кеше күмелеп, кайберләре хәтта тулысынча таркалып та бетмәгән иде. Гомумән, сөякләрнең ни дәрәҗәдә саклануы аларның нинди балчыкта, туфракта ятуына да бәйле.

– Шушы эшләрне башкарган вакытта иң авыры нәрсә?

– Иң зур каршылык – һава торышы. Ленинград өлкәсе, гомумән, үзенчәлекле. Әле генә кояш була, берничә минуттан аны көне буена пыскып торган яңгыр алыштырырга мөмкин. Элек бирегә Татарстанның студентлар отряды күп йөри иде. Хәзер алар Ленинград өлкәсеннән башка шәһәренә бара. Гомумән, миңа бу эш бик ошый. Урманның үзенең бер тылсымлы ягы бар. Хәзер үземне шушы экспедицияләрсез күз алдына да китермим инде.

Яратсам да...

Үтеп барышлый

Равил САБЫР

– Менә, Равил, сез – язучылар, шагыйрьләр – мәхәббәт турында язарга яратасыз инде. Тик минеке кебек мәхәббәт турында әле беркемнең язганы юк. Хәер, һәркемгә аныкы гына шундый чиста, олы, матур, кабатланмас дип тоеладыр инде ул. Ничек дигән әле Такташ? «Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта...»

Студент чак. Көчләп диярлек театрга алып барганнар иде безне. Кайсына икәнен әйтмим, анысы мөһим түгел. Ә беләсеңме нәрсә мөһим? Минем баш рольдә уйнаган артистканы тагын бер күрәсем килде. Аның уенынан таң калуымны белдертәсем, рәхмәт әйтәсем, чәчәкләр бүләк итәсем килде. Шуңа күрә икенче көнне тагын театрга барырга уйладым, шул ук спектакльне карарга.

Кешегә сөйләсәң, кеше ышанырлык түгел – өч сәгать җыендым чыгып киткәнче! Чалбарның стрелкасына кагылсаң, бармакны кисәрлек! Өр–яңа ап–ак күлмәк белән кычкырып торган кып-кызыл галстук алып кидем. Затлы исемлек сибендем. Ниһаять, киттем театрга!

Барганда, күзалдыма китереп барам. Менә мин зур букет күтәреп, театрга килеп керәм. Фойедагы тамашачылар барысы да миңа карый! Спектакль башланып, теге артистка сәхнәгә чыккач, алар чәчәкләрнең кемгә икәнен аңлап алалар да карашларын тагын миңа ташлыйлар. Мин бит оялып үләчәкмен, дим!

Барып җиттем. Кассага керсәм, йә Алла, билетлар юк! Чыктым урамга. Бер егет басып тора. Сөйләшеп киттек. Кызын көтә икән, тегесе һаман килми! Ятып калганчы, атып калыйм, дип кенә, билетыңны сат әле, дигән идем, сәгатенә карады да, мә, болай бирәм, ди. Рәхмәт әйтергә дә өлгермәдем, кисәк борылып китеп тә барды бу.

Мин дә сәгатькә күз салдым. Спектакль башланырга җиде минут калган. Чәчәк кибетенә җитешмим бит инде, кереп киттем театрга. Ярар, минәйтәм, тәнәфестә фойедагы киосктан сатып алырмын әле.

Тәнәфестә киоск янына килсәм, ни күзем белән күрим, нибарысы бер генә роза калган! Күз явын алырдай чибәр артисткага хризантема белән гладиолус бүләк итә алмыйм ич инде мин?! Берни эшләр хәл юк, киттем инде чәчәк кибетенә. Булган бөтен акчаларымны кибетче кызга чыгарып салдым да, шушы суммага букет ясап бирегез, минәйтәм! Шундук тагын бер сатучы кызны чакырып китерде бу. Нидер пышылдаштылар да бәлки сезгә кәрзингә композиция ясап бирергәдер, диләр. Ясагыз, минәйтәм. Их, егетләр, бу дөньяның бер бәхетсезләре сез, чөнки ул чәчәкләрне күрмәдегез! Минем үз гомеремдә алай матур итеп җыелган композицияне күргәнем юк иде! Ә исләре... Башларны әйләндерә!

Урамга чыксам, йә Алла, аңысын уйламаганмын, сыерчык бураны котыра иде ич! Нишләргә? Театрга барып җиткәнче, чәчәкләр өшеп бетә бит. Такси ялларга мәзәк, театр якында гына, аннан соң акча да бетте бит инде. Озак уйланып тормадым, пәлтәмне салдым да чәчәкләрне шуның белән капладым. Барам театрга, мин сиңа әйтим, җил сөякләргә кадәр өшетте, ә миңа рәхәт. Мин бит Аңа дөньядагы иң матур чәчәкләрне алып барам!

Килеп кердем театрга. Гардеробтагы мәгънәле генә итеп елмаеп куйды. Залга керә торган ишек янында билет тикшеручә апа тора иде. Ул да чәчәкләрне күргәч, улым, менә монда ишек янына гына куеп тор, әнә тегендә якында гына буш урын бар, шунда утыр, дип, бик җылы каршы алды. Кереп утырдым. Ышанмассыз, егетләр, йөрәк дөп-дөп тибә, кул-аяклар калтырый башлады.

Ниһаять, спектакль тәмамланды. Халык басып кул чаба башлады. Мин чәчәкләремне алып сәхнәгә чыкмакчы идем, аякларга унар потлы герләр бәйләп куйганнар диярсең, батырлыгым җитми ничектер. Шунда берәрсе чыкса, мин дә чыгар идем, тик берәү дә кузгалмый. Сәхнәгә килеп җитәр-җитмәс туктаганннар да, алар да ул кадәр кул чабуга аптырап, сәхнәгә чыгарга базмыйча торалар. Бу мизгел миңа гасыр булып тоелды!

Ярый әле бер ханым чәчәк күтәреп сәхнәгә менеп китте, йөрәгем тотып егыла идем, югыйсә. Ул ханым артыннан тагын берничә кеше күтәрелде. Нишләптер берсе дә бу артисткага чәчәк бирмәделәр. Ул бу хәлгә ничектер уңайсызланыбрак тора иде, ни дисәң дә, төп рольне башкаручы бит. Ниһаять, мин дә айнып киттем, кәрҗинемне алып, сәхнәгә юнәлдем. Минем сәхнәгә чыгуым гына булды, актерларның берсе үзенең букетын аңа бирде. Ул мизгелдә мин бу егеткәйне ботарлап атырга әзер идем!

Адымнарымны тизләтә төшеп, аның янына килдем дә алдына чәчәк тулы кәрҗинемне куйдым. Аннан соң гусарларча бер тиземә тезләндем дә... кулын үптем. Чынлап әйтәм, Равил, ни өчен алай эшләгәнемне хәзер дә белмим, аңлата алмыйм. Күрәсең, залның гомуми күтәренке кәефе миңа да күчкәндер. Зал димәктән, тамашачыларның инде кимүгә таба барган кул чабулары минем гамәлемнән соң ничектер икенче дулкын булып, беренчесеннән күпкә көчлерәк булып ишетелә башлады.

Мин аңа: «Рәхмәт сезгә, туташ, сез – зур талант!» – дидем дә сәхнәдән китәргә ашыктым. Гардеробтан пәлтәмне алдым да йөгереп диярлек урамга чыктым. Анда һаман сыерчык бураны котыра иде. Мин йөзем белән җилгә каршы бастым. Зур юеш кар бөртекләре кызган битемә бәрелеп еладылар. Белсәгез иде, егетләр, нинди бәхетле идем мин ул мизгелдә! Андый бәхетле минутны дөньяда беркемнең дә кичергәне юктыр...

Менә шуның белән вәссәлам минем мәхәббәт тарихы, Равил. Ничек дип әйтим икән?.. Аның хәтерендә зур кәрҗин тутырып чәчәкләр бүләк иткән егет буларак, инде пафос белән әйтсәк, хыял булып кына калсам, яхшырак дип санадым... Нидән курыктыммы?! Аның янәшәсендә бик тупас һәм ямьсез булып күренүдән... Гөлчәчәк янында алабутага урын юк, аны барыбер төбе-тамыры белән умырып аталар. Ничек аңлатыйм икән? Чәчәк бүләк итү ул – минем күңелемнең бер очынып алуы гына иде. Бу бары тик театрда бик шәп итеп уйнаган гүзәл кызга минем рәхмәтемне җиткерүем генә. Бу очракта шуннан да артыгы була алмый...

Ничек дип җырлый әле «Айфара» егетләре? «Син йолдызга ник үрелим, яратсам да дәшмәдем...» Менә шулар турында яз син, Равил, чын язучы булсаң...

Кай җирең авыртса – шул яман, дигән безнең бабайлар. Чыны да шул: башың авыртса да, күзеңә берни күренми, тешең сызласа да – эш харап, эчең борса, тагын да яман. Шундый чакларда табиблар сиңа фәрештә булып тоела башлый.

Авырткан җир

Узган язда кояшның тәүге нурлары тәрәзәмә төшкәч тә: «Яз житте!» – дип сөенеп, форточканы ачык тоткан идем, ашыкканмын, күрәсең. Кичкә температурам күтәрелде, башым авырта башлады, җеп өзәр хәлем дә калмады. Дару эчкәч, азрак җиңеләеп тора да, төймәнең көче беткәч, чир тагын һөҗүмгә күчә. Аның белән шулай берничә көн көрәшеп карадым да, алга китеш сизелмәгәч, «Ашыгыч ярдәм» чакырттык. Хастаханәдә рентген ясап, «үпкә ялкынсынуы» дигән диагноз куйдылар, дәвалау курсы билгеләделәр.

Каләм иясе, нинди генә хәлдә булса да, үз һөнәренә тугры кала. Мин дә үзем шикелле авыруларны күзәтеп ята башладым. Каршы караватта шактый таза бәдәнле, түгәрәк йөзле, сөйкемле татар карчыгы ята. Ул монда тик ятуына, оныкларына ярдәм итә алмавына бик борчыла. Беренче күргән кешесе булса да, эч пошуын минем белән дә уртаклашты. Тик, нишләптер, көнләп түгел, ә сәгатьләп авырая иде аның хәле. Баштарак бөтен процедураларга йөгереп йөргән күршем күзгә күренеп хәлсезләнә барды. Сөйләшә торгач, аның якташым булуы да ачыкланды. Тора-бара түгәрәк йөзендә әнием чалымнарын да таптым. Һәм ул апа миңа монда иң якын кешемә әйләнде. Система алгач, үземнең хәлем күзгә күренеп әйбәтләнә башлады. Инде чал чәчле апа өчен борчылам. Аны да минем шикелле үк үпкә ялкынсынуыннан дәвалыйлар, ингаляция дә ясыйлар. Ләкин медик булмасам да, белеп торам: күршемдә үпкә чире түгел, аның тыны кысылуы, ютәлләве йөрәге авыртканнан. Гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган әнием дә интекте йөрәк белән. Шуңа әлеге чирдән җәфаланучыларның нинди кыяфәттә булуларын яхшы беләм. Биредәге табиблар шуны белмиме икән дим?

Кичкә аның ютәле тагын да көчәйде, тын алуы тагын да авырлашты. Шәфкать туташын эзләп киттем. Килеп укол кадап, ингаляция ясагач, хәле әйбәтләнде кебек бераз, бер-беребезгә тыныч йокы теләп, урыннарыбызга яттык. Ләкин тыныч төн язмаган икән. Кемдер төртеп уяткандай сискәнеп, күземне ачсам, әбием урын өстендә хәл эчендә утыра. Чал чәчләре тузгыган, йөзе, тәрәзәдән төшкән ай яктысыннандырмы, тагын да агарып калган, үзе көчкә тын ала. Күзләре дә тонықланган. Янәшәмдә генә әҗәлнең салкын сулышын тойгандай булдым. Эшнең нидә икәнен, күршемә кичекмәстән ярдәм кирәген аңлап сикереп тордым да кулыннан тоттым, алар сап-салкын иде. Димәк, һәр мизгел исәптә... Әниемне дә шулай югалттым бит инде мин...

Коридор буйлап, кизү торучы шәфкать туташын эзләп киттем, тапкан идем, ишеге бикле булып чыкты. Биш минутлап шакылдатып торганнан соң, ишек ачылып китте һәм шәфкать туташының ачулы йөзе күренде. «Нәрсә булды?» – диде ул, татлы йокысыннан уятканга канәгатьсезлеген белдереп. «Инфаркт була күрмәсен, кардиобригада чакыртыгыз, юкса, бүлегегездә мәет булырга мөмкин», – дип тә өстәдем. «Сез табибмы әллә? Белгәне-белмәгәне дә өйрәткән була...» – дия-дия, миңа иярде. Аңа комачауламыйм дип, мин палатага кермәдем. Бер тын коридорда уйларыма чумып утырдым...

Шәфкать туташын да аңларга тырышып карадым: көн дә, төн дә гел бер төрле эш: укол када, чирле-чорлының бетмәс зарын, ыңгырашуын тыңла, төн йокыларыңны калдырып, мең дә бер чиргә каршы тор. Бүген дә шул, иртәгә дә, берсекөнгә дә. Эшен алмаштырмаса, гомере буе шулай. Шулчак күңелемдә тагын бер фикер баш калкытты һәм шәфкать туташы мина бик кызганыч тоелды. Эшеңне яратмасаң, теләсә нинди һөнәр газапка әйләнә бит ул. Яшәү бәхетенең асылын эшеңә сөенеп бару һәм өеңә шатланып кайтуда дип аңлаталар.

Ул арада уйларымны таратып, ак халатлы табиблар йөгерешеп йөри башладылар. Кардиобригада да килеп җитте һәм күршемне башка хастаханәгә күчерделәр. Чынлап та, йөрәге авырткан булган аның. Иртән бүлек мөдире рәхмәт әйтте үземә – үлем-китем була калса, башланган сыйпамыйлардыр аларның да. Әмма безгә адәм балаларына, теләсәң-теләмәсәң дә, шул ак халатлылар янына барырга туры килә.

Язмамны язып бетереп соңгы ноктасын куйганда, редакциябезгә бер хат килеп төште. Аны Казан шәһәреннән Гәүһәр Хәснетдинова җибәргән. Ул анда үзенең 83 яшьлек әнисе Миңнуллина Бриллиантны Казан шәһәренең 7нче клиник хастаханәсендә бик яхшылап дәвалаулары турында язган. «Мондый хастаханәләр киноларда гына була дип белә идем. Шөкер, бездә дә бар икән андый дәвалау йортлары һәм аларда, кешенең кем булуына карамастан, беренче ярдәм дә күрсәтелә икән. Ишектән килеп керү белән, әнигә төрле тикшерүләр үткәрделәр, диагноз билгеләп, кичекмәстән дәвалый да башладылар. Хәтта эше тыгыз булса да, нейрохирургия бүлеге мөдире үзе карады, күз табибы да тикшерде. Андагы шартлар, җылы мөнәсәбәт әниемне тиз савыктырды. Юкка халык: «Табиб дару белән генә түгел, ягымлы караш, җылы сүз белән дә терелтә», – димиләр. Бәхетебезгә, табибларыбыз шундый булып чыкты. Бигрәк тә дәвалаучы табиб Хәлиуллин Азат Хәмит улына рәхмәтебез чиксез. Авыр, җаваплы, игелекле хезмәтеңдә уңышлар гына озатып йөрсен үзең!»

Бу хат күңелдәге өметемне дөрләтеп җибәрде.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

«ШӘҺРИ КАЗАН»нан – алма бакчасы

Бу язылу кампаниясендә укучыларыбызны нинди бүләк белән сөендерик икән, дип озак уйландык. Үзе файдалы да, истәлекле дә, матур да булсын иде ул бүләк. Уйлый торгач таптык тагын: без сезгә, Югары Ослан районының Ямбулат авылындагы «Заря» питомнигы белән берлектә, алмагач үсентеләре бүләк итәбез!

Бүләк алуның әллә ни кыенлыгы юк. Газетадагы анкетаны тутырып, 2017 елның II яртыеллыгына язылу турындагы квитанцияне редакциягә җибәрергә һәм жирәбә нәтиҗәләрен генә көтәргә кирәк. Үзегезгә ничек җайлы, шулай эшләгез, без аларны почта аша да, электрон адресыбызга да, «ватсап» аша да, социаль челтәрләрдәге төркемнәребездә дә кабул итәбез. Бүләк ике атна саен уйнатыла. Жирәбә уйнатуны видеога төшереп, **www.shahrikazan.com** сайтында урнаштырачакбыз.

Әйдәгез, алма бакчасында «Шәһри Казан» укыйк әле!

ИНДЕКСЛАР
П2430 – пәнҗешәмбе саны, ярты елга язылу бәясе – **450 сум.**

П2395 – атнага өч тапкыр: сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга, ярты елга язылу бәясе – **930 сум.**

Бүгенге көнгә редакция адресына 13 хат килде. Без аларның һәркайсын номерлап бардык һәм очраклы саннар генераторы ярдәмендә, беренче алмагач үсентесенең хуҗасын сайлап алдык. Видеоязманы shahrikazan.com адресы буенча, газетабызның сайтына кереп карый аласыз. Беренче бүләк хуҗасы – 11 саны астында Әлки районы Карга авылыннан Гөлсинә ГАЛИУЛЛИНА. Котлыйбыз! Чираттагы җиңүчене 17 май көнне билгеләячәкбез.

АНКЕТА

1. Исем-фамилия, адрес, телефон ___

2. Яшегез ___

3. Шөгылегез ___

4. «Шәһри Казан» газетасын кайчаннан бирле алдырасыз? ___

5. Газета белән беренче тапкыр ничек һәм кайда таныштыгыз? ___

6. Газетага ничек языласыз:
почта бүлекчәсендә ___
хат ташучы өйгә килә ___
интернет аша ___

7. Газетаны кайсы битеннән укый башлыйсыз? ___

8. Сезне нинди эчтәлектәге язмалар җәлеп итә? ___

9. Газетада тагын нинди темаларның күтәрелүен телисез? ___

10. Газетаның миңа иң ошаган: ___

ошамаган яклары: ___

11. Тагын нинди газета-журналлар алдырасыз? ___

Язып → Анкетаны тутыр → Җибәр

Язып
«Шәһри Казан» газетасына почта бүлекчәләрендә яки интернет аша язып

Анкетаны тутыр

Җибәр
Анкета, квитанцияләр, «Алмагач» дигән тамга белән, түбәндәге адресларга кабул ителә:
Почта аша: 420066, Казан, Чистай урамы, 5нче йорт, «Шәһри Казан» редакциясе
Электрон почта: shahri-kazan@tatmedia.com
Ватсап: 8 917-851-69-62
Социаль челтәрләрдәге төркемнәр:
vk.com/shahrikazanda
facebook.com/shahrikazan
ok.ru/shrikazan

Газетага ничек язылырга?

1. ТАТАРСТАННЫҢ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ПОЧТА БҮЛЕГЕНДӘ

2. Казан шәһәрендә өегезгә дә килеп яздырабыз. Моның өчен **562-50-12** яки **8-917-851 69 62** номерларына шалтыратып, заявка калдырырга кирәк

3. ИНТЕРНЕТ АША – ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ПОРТАЛЫНДА

Моның өчен кул астында интернетка тоташкан берәр җайланма булуы гына кирәк
1. **uslugi.tatarstan.ru** сайтына кер;
2. «Подписка: газеты и журналы» дигән төймәгә бас;
3. Шәхси кабинетыңа кер;
4. **«Шәһри Казан»** (электрон каталогта – «Шахри Казан») газетасын сайла;
5. Адресыңны яз;
6. Дәүләт хезмәтләре порталы аша квитанцияне түлә.

Реклама

Тулырак мәгълүмат shahrikazan.com сайтында

Бер капчык арыш бер КАМАЗ тиресне алмаштыра

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Тәрәзә төпләрен помидор, борыч, баклажан үсентеләре бизи. Махсус җайланмалар белән тәрәзә төбенә үсентеле тартмаларны өчәр кат тезүчеләр дә бар хәтта. Берничә ел элек үстереп торасы да юк, кибеттән сатабыз да алабыз, диючеләр дә кабат бакчачылыкка кайттылар.

Сәбәпләре бик гади. Беренчедән, кибеттәге бәяләр халыкның акча янчыгына туры килми. Икенчедән, үзең үстергән – сыйфатлы һәм экологик яктан чиста. Хәер, тиз үстерәм, бакчамны корткыч, чүпсез итәм дип, үз бакчаңны да агулап бетерергә мөмкин анысы. Бүген нинди генә ашлама, дару тәкъдим итмиләр. Без ничек итеп үзебезгә зыян салмый гына мул уңыш алып булу серләрен өйрәнербез. Киңәшчебез – 30 елдан артык Россия авыл хуҗалыгы үзәгенең Татарстан бүлекчәсендә агроном булып эшләгән Нурия Фәйзрахманова. Ул Россия авыл хуҗалыгы үзәгенең «Казан» агросәнәгать паркында урнашкан сату ноктасында бакчачылык буенча киңәшләр бирә, организм өчен зыянлы булган химикатлар кулланмыйча гына халыкны экологик чиста яшелчәләр үстерергә өйрәтә.

Ел саен бәрәңге бакчасында чүп утап интегәбез. Быел бакчаның бер өлешен парга калдырсак диган идек. Нинди культура чәчәргә һәм бу безне чүптән коткарырмы?

Салисә Галиуллина,
Биектау районы.

Әлеге очракта иң яхшысы – арыш. Арыш барлык төр диярлек чүп үләннәрен бетерә һәм туфракны бик нык яхшырта, йомшарта. Юкка гына, бер капчык арыш бер КАМАЗ машинасы тиресне алмаштыра, димиләр. Арыш шулай ук черек авыруларыннан, бәрәңгене боза торган проволочниктан да ярдәм итә. Аны уңышларны җыеп алгач та чәчеп, туң төшкәнче җирне кәрәк белән йомшартып куярга була. Ә инде җирне ял иттерү мөкинлеге бар икән, тагы да яхшы. Яз көне чәчегез дә көзен җирне эшкәртерсез, өлгергән орлыклар әле язга кабат тишелеп чыгып, кабат җирне ашар.

Тагын бер культура белән таныштырып үтәсем килә, бу – горчица. Аны әле дә чәчәргә соң түгел. Помидор, борыч, баклажан өчен калдырылган мәйданнарга горчица чәчсәгез, ул тишелеп чы-

гып җирне дәваларга өлгерә. Горчица да чүп үләннәреннән коткара, черек, гөмбә авыруларыннан туфракны дәвалый. Аны бер сезонга өч, дүрт тапкыр чәчәргә була.

Алтын куз дигән бөҗәк турында аңлатып язгыз әле. Аны сатып алып бакчага җибәрәләр дип ишеткәнем бар. Ничек була ул?

Наил Саттаров,
Арча районы.

Алтын күзне бакчачыларның иң якын ярдәмчесе дияргә була. Ул үзенең әнәсе белән корткычларны ын личинкада чагында ук юк итә. Аның менә шундый үзлегеннән чыгып, Россия авыл хуҗалыгы үзәгенең Татарстан бүлекчәсе белгечләре алтын күзнең личинкаларын үстерә башладылар. Алар кәгазь пластинкаларда урнаштырылган була. Без аларны өч литрлы банкаларда саклыйбыз, һава йөрсен өчен, өсләре марля белән каплана. Алып кайтып бакчага, теплицага җибәрсәгез, калганын үзләре эшли.

Бик тиздән өйдәге үсентеләрне теплицага чыгара башлаячакбыз. Тирес белән ашласаң, җылыда гөмбә чире, күбәләкләр үрчи. Химикатлар кулланмый гына ничек итеп туфракны ашлап була икән?

Әнвәр Мәхмүтов,
Казан шәһәре.

Сорау бик урынлы. Теплицада гадәттәгедән җылырак була, без аны җилдән дә саклыйбыз, шуңа күрә һәртөрле авырулар монда тиз үрчи. Тиресне дөрес итеп кулланмаган очракта да бөтен уңышны юк итәргә була. Бу очракта мин «Триходермин» препаратын тәкъдим итәр идем. Бу – файдалы гөмбәчекләр. Ул табигатьнең үзеннән алынып махсус үстерелгән. Үсентеләрне утырткачы җирне йомшартканда бераз гына кушсагыз да бик күп төрле мәшәкатьләрдән арынырга була. Ул авырулардан да саклый, үсентеләрнең тиз тамыр җибәреп, үсеп китүенә дә ярдәм итә. Утыртканнан соң да, аз гына суда болгатып, помидор, җиләк, кыяр төпләренә сибәргә була. Иң мөһиме, бу – биологик препарат. Аның бернинди дә зыяны юк. Теплицаны ашлама белән эшкәрткәндә, ул яшелчәләрне ашаганчы, шунда кереп эшләгәндә үк зыян сала. Пар белән сез үзегез дә агу сулаячаксыз.

Суганнан уңыш ала алмыйм. Сәбәп нидә икән?

Лилия Идрисова,
Казан шәһәре.

Сәбәп – орлыкка дигән суганның ничек саклануында. Карап торышка ул бик әйбәт кебек күренергә мөмкин, ә уңыш юк. Шуңа күрә орлык суган сатып алганда бик очсыз бәягә алданмагыз. Саклану шартлары белән кызыксыныгыз. Монда температураның, дымлылыкның да шартларга туры килүе бик мөһим. Без үзебез сату өчен орлык суганны тикшерелгән, ышанычлы партнерлардан гына алабыз.

Бакчабыз урманга якын. Кыр тычканнары, сукыр тычкан, урман тычканы – бар да зыян сала. Җир кардан арынгач, хәйран калдым, газонны казып, әллә нинди юллар салып бетергәннәр. Агу кулланырга куркам.

Әлфия Гәлләмова,
Яшел Үзән.

Мондый сорау белән мөрәҗәгать итүчеләр гел булып тора. Яшь балалары, кош-кортлары булган гаиләләр өчен агу куллану аеруча куркыныч. Тычкан-күсе белән көрәшәм дип, үзеңнеке булмаса, күршеләреңнең тавыкларын, чебешләрен юк итәргә мөмкин. Соңгы елларда җәйге чорда бакчаларында тавык-чебеш тотучыларның да саны арта, белгәнебезчә, кимерүчеләр агуны ашаган җирдә ятып үлмиләр. Бүгенге көндә белгечләр яңадан-яңа препаратлар тәкъдим итеп торалар. Шуларның берсе «Денисюк, Пр». Өстеннегә – ул бары тик кимерүчеләргә генә тәэсир итә. Составында кимерүчеләр организмына зыян сала торган элементлар бар. Препаратны ашаганнан соң тычкан, күсе авырып үлә. Бу авыру башкаларына да иярә.

Рәхәт мәшәкать

Резеда Бикбулатова (Мифтахова) Арча районында әле яңа кеше. Гомеренең күп өлешен Мәскәүдә уздырган. Шунда эшләгән, балалар үстергән. Әти-әниләре Арчага күченеп кайтканнан соң, терәк, иптәш булыйк дип, алар да, йорт салып, Казан артына күченгәннәр. Кайда гына яшәмәсен, эшләмәсен, Резеда ханым яраткан шөгыленнән аерылмый.

– Кул эшләре – тормышымның аерылгысыз өлешедер. Чигүме ул, бәйләүме – аермасы юк. Мәскәүдә яшәгәндә, хезмәттәшләремнең ирләре чит илгә командировкага йөриләр һәм ул чорларда бик тә дефицит булган «Бурда» журналларын алып кайталар иде. Мин шулардан карап, аларга киемнәр бәйләп бирә торган идем. Беләсезме, бу акча эшлисе килү теләге генә дә түгел, нәкъ менә шулай итеп бәйлисе, булдырасы килү теләге иде. Аннан соң аерым кибетләрдә кыйммәт бәягә бәйләнгән брендлы костюмнар, кофталар сата башладылар. Монда да аз гына хәйләләргә туры килде. Кибеттә киемнәрне киеп фотога төшәбез дә, аннан соң үзебез нәкъ шулай итеп бәйлибез. Бу бит инде күпләп сату өчен түгел, үзең өчен генә, шулай булгач, гаеп булмагандыр. Әйткәнемчә, чигәргә дә яратам. Әнием дә чигүче, – дип сөйләде үзенең яраткан шөгыле турында әңгәмәдәшем.

Кеше затлы әйберگә акчасын кызганмый, дигән фикердә ул.

– Бу әйбер аңарда гына булачак, аның гәүдә төзелешенә туры китереп эшләнә, шуңа күрә һичшиксез килешәчәк, – ди ул. – Хәтта җеп алып, гап-гади оекбаш кына бәйләп сатсаң да, акча эшләргә була. Шунысын да истән чыгармыйк: кул эшләре белән шөгыльләнү кешенең үзе өчен әйтеп бетермәслек рәхәтлек бирә. Ә инде шуның өчен акча да түлиләр икән, нигә бәйләмәскә, чикмәскә? Арчага күченгәннән соң, үзем белгәннәрне башкалар белән дә уртаклашу теләгеннән, кечкенә генә сату ноктасы ачтым. Киләчәктә хыялым – кул эшләре белән шөгыльләнергә теләүчеләр өчен мастер-класслар үткәрү.

Резеда ханым белән сөйләшүдән соң, «Шәһри Казан» газетасы сайтында «Матурлык туганда» дигән бәйге башлап җибәргән идек. Безнең адреска 30га якын эш килде. Конкурсның шартлары буенча, соңга калып килгән эшләрне кабул итә алмадык, 23 кешенең эше конкурста катнашты. Җиңүчене тавыш бирү юлы нәтиҗәләре белән сайлап алдык. Менә алар:

1нче урын – Ләйсән АБДУЛЛАЕВА (55 930 тавыш)
2нче урын – Лилия ШӘМСЕТДИНОВА (45 928 тавыш)
3нче урын – Чулпан ГАЛИЕВА (44 747 тавыш)

Әлеге конкурс укучыларыбызга аеруча ошады. Катнашырга теләк белдерүчеләр дә бик күп. Көзгә таба, бер кат бакча эшләре беткәч, без аны кабат үткәрербез.

СӘЛАМӘТЛЕК

Әй башым...

Башы авыртмаган кеше бармы икән? 90 процент кеше үз гомерендә бер тапкыр булса да, баш авыртуыннан интегә. Баш авыртуының сәбәпләре, аны дәвалау ысуллары турында медицина фәннәре кандидаты, Татарстанның Төбәкара клиник-диагностика үзәгенең неврология бүлеге мөдире Марат Сайхунов белән сөйләштек.

Эльвира МОЗАФФАР

– Моннан биш мең еллар элек үк баш авыртуыннан зарланганнар. Борынгы папирусларда да бу хакта мәгълүматлар сакланып калган. Танылган философ, медицинаның «атасы» Гиппократ та үзенең фәнни хезмәтләрендә авыру турында язган булган. Әмма ничек кенә булмасын, бу борынгы авыруга китергән сәбәпләрнең кайберләрен медицина белгечләре бүген дә төгәл генә ачыклап бетерә алмый, – ди Марат Сайхунов.

Медицинада баш авыртуларын ике төркемгә бүлеп карыйлар. Баш авыртуларының 80 процентын тәшкил иткән беренче төркемгә күпләргә таныш мигрень һәм баш мускулларының киеренкелегеннән килеп чыккан авырулар керә. Нәкъ менә соңгысы хәзер кешеләрдә аеруча еш очрый икән: ул күп очракта көндәлек ыгы-зыгы, мәшәкатьләр, борчылу, стресс, күп уйлау, ялсыз эшләү, талчыгу, компьютер каршында хәрәкәтсез утыру кебек сәбәпләр аркасында килеп чыга. Бу очракта баш миендә структур үзгәрешләр күзәтелми. Икенче төркем баш авырулары инсульт, яман шешләр, төрле имгәнүләр, бәрелүләр, ялкынсыну, умыртка баганасының муен өлеше остеохондрозыннан килеп чыгарга мөмкин.

– Статистика күрсәткәнчә, башы авыртып җәфаланучыларның 85 проценты табибка мөрәҗәгать итми. Күпләр, үтәр әле дип, үз белдеге белән дәвалана. Кайчакта, чынлап та, авырту кими, уза сыман. Кайсы очракта табибка барырга кирәк?

– Авыртуны дару басарга мөмкин. Әмма тиешенчә дәвасы булмагач, башның алга таба тагын да көчлерәк авыртуы бар. Кеше даруларның күбрәк эчәргә мәҗбүр була. Шуны да истән чыгармаска кирәк, авыртуны басар өчен аена 15 көннән дә күбрәк дару эчәсең икән, бу үзе үк баш авыртуы китереп чыгара. Әгәр дә кешенең башы аена ике тапкырдан да күбрәк авырта икән, һичшиксез, табибка күренергә, томография тикшерүе узарга кирәк.

Медицинада «кызыл флаглар» дигән төшенчә бар. Ягъни кайбер билгеләр күзәтелгәндә, кичекмәстән табибка барырга киңәш ителә. Әйтик, баш кинәт авырта башлады, ди. Моны пациентлар «яшен суккан шикелле» дип тә чагыштыра. Бу очракта кешенең башына субарахноидаль кан савуы бар. Ягъни тамыр өзелеп, баш мие тирәсенә кан яңгыр кебек ява. Инсульттан аермалы буларак, кеше бу хәлдә йөри, сөйләшә, бары башы гына каты авырта. Бу очракта «ашыгыч ярдәм» хезмәте чакырырга кирәк. Шулай ук озак еллар баш белән җәфаланган кешенең авырту билгеләре үзгәрсә, көчәйсә, сәламәтлек өчен куркыныч.

– Мигрень дигәне нәрсә?

– Мигрень – грек теленнән тәрҗемә иткәндә, «ярты баш» дигәнне аңлата. Бу вакытта нәкъ менә башның ярты өлеше авырта. Мигрень вакытында авырту берничә сәгатьтән өч көнгә кадәр сузылырга мөмкин. Кешенең күңеле болгана, косарга мөмкин. Бу вакытта авырулар яктылыкны, көчле тавышларны кабул итмиләр. Мигрень өянәге еш кабатланмаса да, көчле формада уза. Кеше ятып кына тора. Эшли дә алмый. Кайбер кешеләр 20-30 еллап мигреньнән интексәләр дә, баш авыртуының сәбәбен һәм үзенә ничек булышасын белми. Ә бүген бу чиргә каршы бик нәтиҗәле дарулар бар. Шуңа да табибларга вакытында мөрәҗәгать итәргә кирәк. Баш авырулары хроник чирләр рәтенә керә. Аларны тулысынча дәвалап булмый. Шулай да, махсус дарулар ярдәмендә, авыртуны киметергә мөмкин. Мигрень кайбер очракта нәселдән дә күчә. Мигрень вакытында дөрес тукланырга, аерым диета тотарга кушалар. Кәһвә, какао, газлы сулар, каты сорттагы сырлар, шәраб, сыра кебек аз градуслы алкогольле спиртлы эчемлекләр, ысланган продуктлар баш авыртуын көчәйтергә мөмкин. Кайбер гормональ контрацептивлар да баш сызлавына китерә.

– Кемдер башым чигәдән кыса, кемдер маңгайдан авырта дип зарлана. Бу нәрсәне аңлата?

– Әйе, кайбер пациентлардан, башыма кыршау, каска кидерткәннәр сыман, дигәнне ишетергә туры килә. Әгәр чигәдән кыса икән, баш мускулларының киеренкелегеннән туган авыру турында әйтергә була. Маңгайдан авыртса, димәк, баш сөягендәге бушлыкларга салкын тигән, гайморит, төрле синуситлар кебек ялкынсынулар күзәтелергә мөмкин. Башның арткы өлеше, гадәттә, кан басымы югары булганда, остеохондроз вакытында авырта. Күзләр белән маңгай бергә авыртканда, күздәге кан басымын тикшертергә кирәк. Кыскасы, теләсә кайсы очракта да төгәл диагнозны бары махсус тикшерү узып кына билгеләргә мөмкин.

– Магнитлы көннәрдә баш катырак авыртамы?

– Әйе, магнит давыллары башка тәэсир итә. Әмма аннан да бигрәк һава торышының еш алышынуы, терекөмеш баганасындагы атмосфера басымының кинәт үзгәреп китүе кеше сәламәтлегенә көчлерәк тәэсир итә. Кемнең организмы авырлыкларны ничек кичерә бит. Шуңа да үзеңне акрынлап чыныктырырга кирәк. Көн саен 40 минут тирәсе җәяү йөрергә ияләнегез. Һәркем моны мөмкинлегеннән чыгып эшләргә тиеш. Тир бәреп чыгу – үзенә күрә бер сигнал сыман. Димәк, күнегүләрне көчәйтергә кирәк түгел. Шул рәвешле, организм үзенә йөкләнгән төрле авырлыкларны кичерергә өйрәнә.

– Баш авыртуыннан кемнәр күбрәк интегә?

– Гадәттә, 45-60 яшьтәге кешеләр баш авырта дип зарлана. Шулай да соңгы арада яшьләр арасында да башы авыртучылар бар. Бу нәкъ менә баш мускулларының киеренкелегеннән килеп чыккан сырхау. Хатын-кызлар арасында зарланучылар күбрәк. Статистика буенча, башы авыртучылар арасында өч хатын-кызга бер ир-ат туры килә. Бу хатын-кызлардагы гормональ үзгәрешләр белән дә бәйле. Эше компьютер, саннар, акыл белән бәйле кешеләрдә бу ешрак күзәтелә. Ә менә гел хәрәкәттә булган, физик эш белән шөгыльләнүчеләр сирәгрәк зарлана. Балаларда да баш авыртулары күзәтелә. Беренчедән, аларда да стресс җитәрлек. Икенчедән, бик күп вакыт компьютер артында утыралар. Актив уеннар уйнаучы балалар хәзер бик аз.

– Төрле үлән чәйләре баш авыртуын баса аламы?

– Баса алса, бик яхшы. Тик чәй белән генә авыруны бетереп буладыр дип уйламыйм. Күбрәк хәрәкәт кирәк. Иртә белән гимнастика ясау да бик мөһим. Моны балаларга да кечкенәдән өйрәтсәң яхшы. Кеше эшкә соңга калса да, битен юмыйча китми бит, биш минут булса да күнегүләр ясау гадәткә керсен иде. Эш белән ялны аралаштырырга кирәк дигән сүзләр тапталган булса да, бик мөһим мәгънәгә ия. Бу фән ягыннан да өйрәнелгән. Вакытында кеше ял да итә белергә тиеш. Аннары хәзер күпләр яшәгән көннең кадерен бәяләми, шатлана белми. Ә бит уңай энергия нәтиҗәсендә бүленеп чыккан гормоннар баш авыртуын гына түгел, хәтта яман шеш күзәнәкләрен үтерергә дә сәләтле. Сөенә белергә кирәк.Тыштан гына түгел, эчтән көлеп яшәү мөһим. Дарулар сызлауны басарга мөмкин, ә авыру белән организм үзе көрәшә.

БАШНЫ НИЧЕК ЯЛ ИТТЕРЕРГӘ?

Невролог Марат Сайхуновтан киңәшләр

- ✓ бер урында хәрәкәтсез 15-20 минуттан да озак утырмаска тырышыгыз;
- ✓ эштән соң җылы душ керү файдалы;
- ✓ киеренкелекне бетерү өчен театр, концертларга барып ял итү кирәк;
- ✓ компьютер каршында эшләгәндә, урынны алыштырып, ял итеп алыгыз;
- ✓ эш белән ялны аралаштыра белегез;
- ✓ кеше, кимендә, алты сәгать йокларга тиеш. Шунысы да бар, төнге 12гә кадәрле бер сәгать йокы 12дән соңгы ике сәгать йокыны алыштыра;
- ✓ физик активлык кирәк;
- ✓ саф һавада ешрак йөрегез;
- ✓ кешенең яраткан шөгыльләре булырга тиеш;
- ✓ уңай эмоцияләр белән, канәгать булып, шөкер итеп яшәгез;
- ✓ салкыннарда башыгызга кимичә йөрмәгез. Эсседә шулай ук кояштан сакланырга кирәк;
- ✓ баш авыртканда, табиб белән киңәшләшеп, ибупрофен даруын файдаланырга була.

deti.mail.ru

Велосипедның да үз үлчәме бар

Шәһәр эчендә кар эреп бетте, димәк, велосипед дигән тимер атны иярләргә вакыт. Сәпитләре булмаганнар бәлки нәкъ менә бу вакытта яңасын алу турында хыялланалардыр. Ләкин ике көпчәкле «дус»ны сайлау җиңел түгел. Укучыларыбызга бу авыр эштә ярдәмгә «Велоспорт» кибете хезмәткәрләре ярдәм итте.

Алисә САБИРОВА

ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ҖАНГА – ЯЛ, ТӘНГӘ – ДӘВА

Тимер атта, гадәттә, 18-35 яшьлекләр йөри. Ләкин балалар, олы яшьтәгеләр өчен дә якын спортның бу төре. Олы буын күбрәк, табиб киңәшен тотып, велосипедта җилдерә башлый. Актив ял гына түгел, сәламәтлеккә дә файдалы бит әле ул. Үпкә, йөрәк эшчәнлеге, нерв системасын җайга салуы турында әйтеп тә торасы юк. Шуңа өстәп, педаль әйләндерү аяк мускулларын ныгыта, варикоз авыруын бетерә, ябыктыра, күз күремен яхшырта. Бер сүз белән әйткәндә, файдасыннан кала бер зыяны да юк сәпитнең.

«Велоспорт» кибете җитәкчесе Динар Гыйләҗев тә, шәһәр халкы хәзер машиналардан велосипедларга күчә башлады, ди. Казанлылар ел саен уртача 20 меңгә якын велосипед ала икән.

– Әлеге бизнеста мин инде – алты ел. Шушы вакыт эчендә шәһәр хакимияте, республика җитәкчеләренең велоспортка карашы күзгә күренеп үзгәрде. Казанда велосипед юллары ясадылар, спорт белән шөгыльләнү өчен кирәкле инфраструктура булдырылды. Шәһәр халкы да хәзер велосипедлар белән күпләп кызыксына. Гомумән, казанлылар спортка тартыла башлады, – ди Динар Гыйләҗев.

ИСЕМЕНӘ ТҮГЕЛ, ҖИСЕМЕНӘ КАРА

Базарга чыксаң да, спорт кибетләренә керсәң дә, велосипедның нинди генә төрләре юк. Кемдер чит илнекенә кызыкса, кемдер, үзебездә ясалганнары яхшырак, ди. Чыннан да, нинди маркалы сәпит яхшырак соң?

– Дөньяда бер генә оешма да велосипед җитештерү белән шөгыльләнми. Төрле илдән кайтартылган детальләрне җыялар да, билгеле бер маркадагы велосипед «туа». Россиядә «Форвард» белән «Стелс» оешмалары актив эшли. Аларның бәяләре дә чагыштырмача түбән. Товарлары да яхшы. Ләкин алар сәпитнең рамнарын гына ясый. Калган детальләр Япония, Кытай, Тайвань заводларыннан кайтартыла, – ди сатучы Руслан Филипов.

Руслан сүзләренчә, хәзер күп кенә зур оешмаларның товары Кытайда җитештерелә. Тулысынча шушы илдә генә ясалган сәпитләргә ышаныч юк, ди ул. Алар тиз ватыла, сәламәтлеккә куркыныч яный икән. Ләкин «фабричный Кытай» дигән төшенчә дә бар әле сатучыларда. Данлыклы чит ил брендлары Кытайга үз товарларын эшләргә заказ биргәндә килеп чыга ул. Әйтик, АКШның «Джаинт» велосипедлары Америкада уйлап табыла, дизайны төзелә, ләкин детальләре Кытай заводында эшләнә. Андый брендларга ышанырга була, ди сатучы.

– Велосипед җитештерү буенча завод ачу дәүләткә отышлы түгел. Шуңа да оешмалар, товарны җитештерү өчен, Кытайга мөрәҗәгать итә. Ул – бу өлкәдә лидер, бәясе дә очсызрак була. Америка, Германия, Россия, Тайвань, Чехия велосипедлары иң яхшылары дип санала, ләкин алар да Кытайда эшләнелә. Шуңа да иң беренче чиратта кайда эшләнүенә түгел, ә нинди материаллардан җитештерелүенә карарга кирәк, – диде Руслан.

СӘПИТЛӘРНЕҢ ДӘ БУЛА ТӨРЛЕСЕ

Велосипед сайлаганда, иң башта аны нинди максатларда куллануыбызны күздә тотарга кирәк. Кибет ишекләрен ачып кергәч тә, сатучының сезгә биргән иң беренче соравы шушы булачак.

– Паркларда, яр буйларында ял итеп йөрү өчен «круизер» категориясендәге велосипедларны сайларга кирәк. Аларның руле элеккеге велосипедларныкы кебек зур, дугаланып тора. Актив ял өчен иң яхшысы шул. Тизлек яратучылар, велосипедны машина урынына кулланучылар, трассадан йөрүчеләр өчен циклокросс, шоссе яки гибрид велосипедлар кирәк. Аларның көпчәкләре юка, шуңа да асфальт юлда югары тизлек җыя. Тигезсезлекләр, урман юлларында йөрү өчен хардтейл велосипедлар кирәк. Бу сәпитләрнең, киресенчә, көпчәкләре киң, алгы һәм арткы амортизацияләре көчле. Аларны икенче төрле «внедорожник» дип йөртәләр әле. Спорт өчен велосипедларны да төрәнә карап сайлыйсың, – ди Руслан.

Юрганыңа карап, аягыңны сузасың, диләрме әле, шуңа да сатучы биргән икенче сорау – ул бәягә барып тәртеләчәк. Беренче карашка бер-берсеннән аерылмаган ике велосипедның берсе – 10, икенчесе 30 мең торырга мөмкин.

– Кыйммәтрәк велосипедның тизлек күчерү җайланмасы, көпчәкләре яхшырак булырга мөмкин. Димәк, җитештерүче аңа сыйфатлырак детальләр куйган, йөрү өчен ул җайлырак. Велосипедның рамы да бәясенә йогынты ясый. Тимердән ясалган рамлы сәпит очсызрак, ләкин ул авыррак, тизлекне дә акрын җыя, сыйфаты да түбәнрәк. Алюминийдан ясалган рамнар сыйфатлырак та, җиңелрәк тә, әмма бәясе кыйммәт йөри, – ди Руслан.

ВЕЛОСИПЕД ХИСАП ЯРАТА

Кибеткә барганчы, буеңны үлчәргә дә онытма. Моннысы нәрсәгә инде тагын диярсез. Кием кебек, һәр велосипедның да үз үлчәме була икән әле.

–12 яшькә кадәр балага велосипедны көпчәк диаметры буенча сайлыйлар. Дүрт яшькә кадәр көпчәк диаметры 12 дюйм булырга тиеш. 4-6 яшьтә – 15, 6-9 яшьтә – 19, 9-13 яшьтә 22 дюймлы көпчәк сайларга кирәк. Олыраклар велосипедны буй озынлыгы һәм рам зурлыгы буенча сайлый. Әйтик, буе 150-165 см лы кешегә 40,6 см лы рам туры килә. Велосипедның, кимендә, өч төрле үлчәме була, – ди Руслан.

Инде велосипед алгач, вак-төякләргә дә күчәргә була.

– Кем өчендер пычрак чәчрәүдән саклый торган рамнар кирәк, ә кемдер бары коры җирдән генә йөри. Көпчәккә һава суырта торган насос алу-алмауны да сатучы үз карамагында калдыра. Ә менә төнлә йөргәндә, сез юл хәрәкәтендә катнашкан башка кешеләргә күренсен өчен, һичшиксез, махсус утлар кирәк. Башлык алырга да киңәш итәм. Үзем дә велосипедта йөрим. Әлегә башлык кимичә йөргән өчен полиция хезмәткәрләренең туктатканын күргән юк. Ләкин велосипедчы сәламәтлеге турында үзе кайгыртырга тиеш. Беренчедән, бездә әле велосипед юллары шәһәрнең бөтен җиренда дә юк. Икенчедән, машина йөртүчеләр үзләре дә велосипедчыларга уңай карамый. Шуңа да сакланганны Алла саклар, – ди сатучы.

Элек мин велосипедны ир-егетләрнеке дип уйлый идем, баксаң, җитештерүчеләр егетләр өчен велосипед бөтенләй чыгармый икән. Егетләр өчен унисекс (ирләргә дә, хатын-кызларга да бара торган) велосипедлар гына чыгарыла. Ә менә хатын-кызлар өчен сәпитне гүзәл затның бөтен анатомиясен өйрәнеп, аның холкына, фигурасына карап ясыйлар ди.

✓ Велосипед йөртүче юл хәрәкәтендә катнашучы дип санала, шуңа да ул юл йөрү кагыйдәләрен үтәргә тиеш.

✓ Кагыйдә буенча, 14 яшьтән соң бала машина юлына чыга ала.

✓ Әгәр дә җәяүлеләр юлы яки велосипед өчен махсус юл булмаса, велосипедчыга юлның уң ягыннан бару мәҗбүри.

✓ Велосипедчылар юлда бер-берсе артыннан барырга тиеш.

✓ Велосипедчы «теле»: туп-туры сузылган сул кул – сул якка борылу; сул кул терсәктән бөгелеп өскә караса – уң якка борылу, өскә күтәрелгән сул кул – туктау.

Рамның размеры, дюймнар	Сезнең буй, см	Рамның размеры, см	Рамның размеры, шартлы бәрмәлек
13"	130-145	33	XS (Xsmall)
14"	135-155	35,6	XS (Xsmall)
15"	145-160	38,1	S (small)
16"	150-165	40,6	S (small)
17"	156-170	43,2	M (medium)
18"	167-178	45,7	M (medium)
19"	172-180	48,3	L (large)
20"	178-185	50,8	L (large)
21"	180-190	53,3	XL (Xlarge)
22"	185-195	55,9	XL (Xlarge)
23"	190-200	58,4	XXL (XXlarge)
24"	195-210	61	XXL (XXlarge)

Җәһәннәмгә юл түләүле

Җәһәннәм дигәч, безнең күз алдына куркыныч ут килеп баса. Әмма ул без белгән уттан күпкә хәтәррәк, хәдисләрдә язылганча, 69 тапкырга көчлерәк икән. Тәмуг уттан торса да, анда агач та бар. Җәһәннәм турында тагын нәрсәләр мәгълүм? Әлеге сорау белән мин даими әңгәмәдәшем – «Өмет» мәчете имам хатыйбы Равил хәзрәт Бикбаевка мөрәҗәгать иттем.

ИМАНЛЫ СҮЗ

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА



– Аллаһ җәннәт һәм җәһәннәмне бу дөньяда тереклекне бар иткәнче барлыкка китерде һәм аларның икесен дә тутырачакмын, диде. Тәмуг бар һәм без моңа ышанабыз. Үлемнән котылып булмый, ә җәһәннәмнән – була. Адәм баласы хәзердән үк үзенең гамәлләре турында уйланырга тиеш, Аллаһның әмерләрен үтәп, җәннәткә эләгергәме, яисә, Аллаһ кушканнарга каршы килеп, утка керергәме – үз юлын ул үзе сайлый. Раббыбыз безгә, туры юлга күнәр, вәгазьләнер өчен, Коръәнне иңдерде, Пәйгамбәрен җибәрде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.): «Җәннәткә нинди юл алып бара, барысын да күрсәттем. Җәһәннәмгә юллар нинди, анысын да белдердем», – диде.

Җәһәннәмгә кергән кешеләр: «Йа Раббым, дөньяга кире кайтарсаң иде, без анда изге гамәлләр генә кылыр идек», – дип мөрәҗәгать итәрләр. Әмма Раббыбыз, сез тагын шул хәлегездә кайтыр идегез дип, аларны кире кайтармас.

– Нишләптер, җәннәт – күктә, ә җәһәннәм җир астында тирән чокырда кебек. Алар чынлыкта кайда урнашкан?

– Ул Аллаһы Тәгаләгә генә билгеле. Пәйгамбәребезнең, җәһәннәмне кыямәт көнендә 70 мең фәрештә тартып китерәчәк, дигән сүзе бар. Ул кешеләр өстенә авамавам дип торачак. Аллаһы Тәгалә сират күперен дә шул җәһәннәм өстеннән куячак. Тәмуг җиде катлы. Аның төбендә монафыйклар яначак. Тәмугның иң өске каты – гөнаһлы мөселманнар өчен. Сират күпере дә шул югары кат аша үтә. Сират күпереннән кешеләр гамәлләренә карап үтәрләр. Бер ишләре аны күз ачып йомганчы, икенчеләре яшен шикелле, өченчеләре чапкан ат кебек үтәр, кайберләре егыламегылмыйм дип кенә атлар. Ә кайберләрен җәһәннәмнең ыргаклары эләктереп алып калыр. Иң югары катта гөнаһлы мөселманнар җыелачак, алар күпмедер газаплангач, җәннәткә чыгарылачак. Шуңа да ул кайчан да булса бетәчәк. Анда беркем дә калмаячак. Ә иман китермәгән кешеләр исә җәһәннәмнең башка катламнарында мәңге кала.

– Хәдисләрдәге гөнаһлы мөселманнарның шәфәгать кылынуы дигән сүз шул тәмугтан чыгарылуны аңлатамы?

– Әйе, кыямәт көнне Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с) һәм башка пәйгамбәрләр, фәрештәләр, изге кешеләр, Аллаһның рөхсәте белән, аларны шәфәгать итәчәкләр. Хәтта изге кешеләр, җәннәттә үзләренең иптәшләрен күрмәгәч, Аллаһка, без бергә мәчеткә йөрдек, намаз укыдык, алар кайда, дип сорар. Аллаһы Тәгалә ризалыгы белән, бу кешеләргә иптәшләрен җәһәннәмнән алып чыгарга рөхсәт ителер.

– Җәннәттәгеләр җәһәннәмдә газапланучыларның тавышларын ишетәме?

– «Саффат» сүрәсендә җәннәт кешеләренең җәһәннәмне күрүләре әйтелә. «Җәннәттәге мөэмин әйтер: «Ул терелеп кубарылуны инкяр итүче иптәшемне җәһәннәмнән күрсәтимме?» һәм җәннәттә булганы хәлдә җәһәннәмгә карап, әлеге иптәшен ут уртасында күрер. Уттагы иптәшенә кычкырып әйтер: «Валлаһи, син мине ышанмаска өндәп үзең кеби утка салырга якын булдың. Әгәр Раббым миңа иманны ингам итмәсә, әлбәттә, сезнең белән бергә мәңгегә утка салынган булыр идем».

– Пәйгамбәребез (с.г.с.)-нең җәһәннәмдә хатын-кызларның күп булуы турындагы хәдисен дә сөйләп китегез әле.

– Пәйгамбәребез, җәннәтне күрдем, анда зәгыйфь һәм фәкыйрь кешеләр күп иде, аннары җәһәннәмне күрдем, аның әһелләре күбесенчә хатын-кызлар иде, ди бер хәдисендә. Ни өчен шулай дип сорагач, алар ирләренең кадерләрен белми. Ире аңа гомер буе изгелек кылып та, бер тапкыр кылмый калса, ул хатын: «Мин синнән гомер буе яхшылык күрмәдем», – дип әйтер һәм бик күп теләсә нинди сүзләр белән ирен битәрләп торыр диде. Моннан котылу өчен сәдака бирергә кушты. Сәдака ул – тәмуг утыннан пәрдә. Галимнәр моны җәһәннәмгә беренче керүдә бәлки хатын-кызлар күбрәк эләгәдер дип аңлата. Гөнаһларына карата тиешле җәзаны алганнан соң, җәннәткә керәчәкләр.

– Җәһәннәм Коръәндә тагын ничек сурәтләнә?

– Аның турында бик күп сүрә-аятьләрдә искә алына. Әйтик, «Духан» («Төтен») сүрәсендә җәһәннәм кешеләренең ашавы турында әйтелә. Алар анда зәккум дигән агачның җимеше белән тукланачак. «Хакыйкатьтә, җәһәннәмдә үсә торган зәккум агачының бик ачы җимеше – явызлыгы күп булган имансызларның ашамлыгыдыр. Аны ашаган кешеләрнең эчендә ул су кайнаган кебек кайнар». «Саффат» сүрәсендә ул җимеш турында тагын да куркынычрак сурәтләнә: «Ул зәккум агачының җәһәннәм уты эчендә үскәнлегенә һәм җимеш биргәнлегенә ышанмыйлар, ышанмаулары аларга газап өстенә газап булачак. Ул җимеш әнәле булып, ашаганда тамакны ертыр, ачылыгы тамакны көйдерер. Дөреслектә ул агач җәһәннәмнең төбеннән чыгып үсәдер. Аның җимешләре кабахәтлектә гүя шайтан башларыдыр. Имансызлар, әлбәттә, ул агачның җимешен ашарлар һәм шул ачы җимеш белән корсакларын тутырачаклар». Зәккум агачы белән ризыкланганнан соң, динсезләр, сусаганнарын басар өчен, гөслин дигән эчемлекне эчәләр. Сусаганнары басылмый, киресенчә, су аларның эчләрен көйдерә, тагы да катырак әчәселәрен китерә. Ул суның кайнарлыгыннан аларның карыннарында булган нәрсәләр һәм тиреләре эрер. «Вакыйга» сүрәсендә: «Ул суны комсызланып (сусаган дөяләр кебек) эчәрсез», – диелә. Ятимнәрнең малын ашаучылар турында «Ниса» («Хатыннар») сүрәсендә искә алына: «Золым юлы белән ятимнәр малын ашаган кешеләр ахирәттә, әлбәттә, карыннарына утны ашарлар һәм бик тиз җәһәннәм утына керерләр».

– Җәһәннәм әһелләренең киемнәре булачакмы?

– Анда кием бар. «Хаҗ» сүрәсендә әйтелгәнчә, иман китермәгән кешеләргә уттан киемнәр кисәрләр һәм кидерерләр, җәһәннәмнең кайнар суы аларның башыннан коелыр. Аларның киемнәре утта кыздырылган бакырдан яки сагыздан булып, йөзләрен ут каплар («Ибраһим» сүрәсе). Тәмугта күләгә дә бар, әмма кара төтеннән булган күләгә салкынча булмас. Андагы эсселектән баш мие кайнар. Андагы ут без белгәннән 69 тапкырга көчлерәк. Әмма шулай да җәһәннәмгә эләгүчеләр аннан үлеп котыла алмыйлар. «Фәрештәләр» сүрәсендә, аларга анда үлмәк белән хөкем булмас, үлсәләр, газаптан котылыр иделәр, вә алардан җәһәннәм газабы аз гына да җиңеләйтелмәс, диелә. Аллаһы Тәгалә, һәр кайчан тиреләре янып бетсә, тәннәренә яңадан тире үстербез, газапның катысын татысыннар өчен, ди («Хатыннар» сүрәсе). Әмма тәмуг никадәр генә куркыныч күренсә дә, адәм балалары нишләптер үз-үзләренә золымлык кылып, Аллаһка итагать итмичә, үзләрен җәһәннәмгә әзерли. Тәмугка акча түләп тә барырга ризалар. Тәмәкене, аракыны, наркотикны бушка бирмиләр, акча түләп аласың бит. Ә җәннәткә юл бушка. Намаз укыган, ураза тоткан, мәчеткә йөргән өчен акча түләргә кирәкми. Пәйгамбәребез (с.г.с.)нең, кеше көнгә өч тапкыр Аллаһы Тәгаләдән җәннәткә керүне сораса һәм җәһәннәмнән коткар дип дога кылса, җәһәннәм Аңа, бу бәндәңне миннән азат ит, дип әйтер, ди. Шуның өчен Аллаһның әмерләренә буйсынып, Ул кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә кирәк.

Май аена намаз вакытлары

Көн	Көн исеме	Сәхәр тәмам	Мәчетләрдә укыла	Кояш чыга	Зәвәл	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Дүш	00:42	02:30	04:00	11:40	12:00	16:52	19:22	21:46
2	Сиш	00:33	02:28	03:58	11:40	12:00	16:54	19:24	21:51
3	Чәр	00:23	02:25	03:55	11:40	12:00	16:55	19:26	21:55
4	Пән	00:11	02:23	03:53	11:40	12:00	16:56	19:28	22:00
5	**Җом**	**23:47**	**02:21**	**03:51**	**11:40**	**12:00**	**16:57**	**19:30**	**21:00**
6	Шим	01:49	02:19	03:49	11:40	12:00	16:58	19:32	21:02
7	Якш	01:47	02:17	03:47	11:40	12:00	16:59	19:33	21:03
8	Дүш	01:45	02:15	03:45	11:39	12:00	17:01	19:35	21:05
9	Сиш	01:43	02:13	03:43	11:39	12:00	17:02	19:37	21:07
10	Чәр	01:41	02:11	03:41	11:39	12:00	17:03	19:39	21:09
11	Пән	01:39	02:09	03:39	11:39	12:00	17:04	19:41	21:11
12	**Җом**	**01:37**	**02:07**	**03:37**	**11:39**	**12:00**	**17:05**	**19:43**	**21:13**
13	Шим	01:35	02:05	03:35	11:39	12:00	17:06	19:45	21:15
14	Якш	01:33	02:03	03:33	11:39	12:00	17:07	19:47	21:17
15	Дүш	01:31	02:01	03:31	11:39	12:00	17:08	19:49	21:19
16	Сиш	01:29	01:59	03:29	11:39	12:00	17:09	19:51	21:21
17	Чәр	01:28	01:58	03:28	11:39	12:00	17:10	19:52	21:22
18	Пән	01:26	01:56	03:26	11:39	12:00	17:11	19:54	21:24
19	**Җом**	**01:24**	**01:54**	**03:24**	**11:39**	**12:00**	**17:12**	**19:56**	**21:26**
20	Шим	01:23	01:53	03:23	11:40	12:00	17:13	19:58	21:28
21	Якш	01:21	01:51	03:21	11:40	12:00	17:14	19:59	21:29
22	Дүш	01:19	01:49	03:19	11:40	12:00	17:15	20:01	21:31
23	Сиш	01:18	01:48	03:18	11:40	12:00	17:16	20:03	21:33
24	Чәр	01:16	01:46	03:16	11:40	12:00	17:17	20:04	21:34
25	Пән	01:15	01:45	03:15	11:40	12:00	17:18	20:06	21:36
26	**Җом**	**01:14**	**01:44**	**03:14**	**11:40**	**12:00**	**17:19**	**20:08**	**21:38**
27	Шим	01:12	01:42	03:12	11:40	12:00	17:20	20:09	21:39
28	Якш	01:11	01:41	03:11	11:40	12:00	17:21	20:11	21:41
29	Дүш	01:10	01:40	03:10	11:40	12:00	17:21	20:12	21:42
30	Сиш	01:09	01:39	03:09	11:41	12:00	17:22	20:13	21:43
31	Чәр	01:07	01:37	03:07	11:41	12:00	17:23	20:15	21:45

Ата – йортның матчасы

Син Алла да түгел, әти,
Фәрештә дә түгел, әти.
Син бары – әти, әти!

Җәннәт – әниләрнең аяк астында, диелә изге Коръәндә. Шәригать буенча, әниләрнең хокукы зуррак. Алар турында без күп язабыз. Ә менә безгә җан өрүче, гаилә намусын саклаучы, мал табучы, таянычлы терәкләребез булган әтиләребез ничектер читтәрәк кала кебек. Шулай да безнең халык гаиләдә ата кешенең урынын югары бәяли. Ата хезмәте җилкә, беләк көче күп сорый торган эш булганга, ул – гаиләдә дә иң гайрәтлесе, көч-куәткә ия кеше. Бер үк вакытта ата кеше салкын, аек акыл иясе дә. Ул булмаса, тормышның яме дә, рәте дә юк. Халык моны яхшы аңлаган һәм яшь буынга да атаның кадерен белергә кушкан. «Атасы барның – бәхете бар», «Ата – йортның матчасы», «Ата аркасы – кала аркасы» дигән әйтемнәр дә юкка гына халык теленә кермәгән.

Үземне белә башлаганнан бирле, мин гаиләбездә «әти кызы» булып үстем. Бик кечкенә чакларымда ук әтиемнән Тукай шигырьләрен кат-кат укытканым истә. Хәер, аның үзенең дә шигырьләр язылган зәңгәр тышлы ике блокноты бар иде. Кызганыч, без аларны сакламаганбыз. Әтием көндез терлекләр карап, кичен башка эшчеләр белән чиратлап каравыл торды. Миңа биш яшьләр чамасы чагында ук җәй айларында әтием Әгер басуына каравылга барганда «зур иптәш» итеп мине дә ияртә иде. Урманга баруга, пешкән камырлык җыеп килә иде. И-и аның тәмлелекләре! Таң беленә башлагач та, әтием иртә торып печән чаба, җиләк җыя. Ә инде сыер савучылар килгәч, әтием чапкан печәнен тарантасына сала да, мине җайлап утыртуга, кайтыр юлга чыгабыз. Үзе, сүзсез генә, моңлы көй сузар иде. Иде дим, чөнки бүген инде әтиемнең бу фани дөньядан китүенә дә 15 елга якын вакыт үткән. Ул әле булса туган йортыбызда ишек төбенә басып көтәдер сыман. Аның рухы бүген дә миңа яшәү көче бирә. Сабыр холыклы, аз сүзле, барлык кешегә дә шәфкатьле иде шул ул!

Әтием, Миннеяр Әхмәтшин, Үчәлле авылында Зәйдулла бабам белән Гатия әбиемнең җиде балалы гаиләсендә 1930 елны уртанчы бала булып дөньяга килгән. 12 яшеннән колхозда ат белән сука сукалаган, сабан сөргән, орлык ташыган, урман кисәргә йөргән. Ачлыктан интегеп ФЗӨдән кайткан өчен, аны бер елга Себергә җибәргәннәр. Анда шахтада эшләгән. Юллык акча эшләгәч кенә, туган якка кайту насыйп булган әтиемә. Дүрт елга якын армия сафларында хезмәт итеп кайткач, авылда төпләнеп, әнием Нәзифә белән гаилә коралар. Терлекчелектә 36 ел хезмәт куйган (гомуми эш стажы 42 ел!) әтиемнең рәсеме Почет тактасыннан төшмәде, «Хезмәт ветераны», «Алдынгы терлекче» булды.

Күңелем нечкәргән минутларда әтиемнең фоторәсемен кулга алам. аның белән «сөйләшәм». Күңелемнән васыятьләрен, әйткән сүзләрен искә төшерәм. Кече күңеллелек, миһербанлылык, ярдәмчеллек, кешегә авыр сүз әйтмәү, җитдилек, авырлыкка бирешмәү – болар барысы да бар иде әтиемдә. «Дөньяда урлашудан да хурлыклы нәрсә юк. Хәрам кешене харап итә. Кеше әйберен сорамыйча алмагыз. Һәрбер эштә тәртип кирәк», – дип искәртә иде. Балта остасы булмаса да, хуҗалык кирәк-яраклары, абзар-кураларны да үзе торгызды. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр хәрәкәттә булды, тик утырмады, эш ташламады, дан-шөһрәт дип тә йөрмәде, байлык-муллык артыннан да кумады. Булган тормышыннан канәгать булып, әниемне хөрмәт итеп, тыйнак, сабыр гына яшәде ул.

...Гомер ни арада узып киткән.

Тәкъсимә ГАРИПОВА,
мәгариф ветераны.
Азнакай шәһәре.

«Әти хакы» бәйгесе
Шәһри Казан
БлагоДарение

Кабат өйләнү турында авыз да ачмаган иде әти

Минем әтием Сәлимҗан Хәйруллин Нурлат районының Чишмә бистәсендә яшәүче гап-гади колхозчы – сарык караучы иде. Хәзер аңа – 80 яшь. Әти яшь чагында шук та, чибәр дә булган. Яше җитсә дә, өйләнергә ашыкмаган. Танышкан кызларын әнисенә күрсәтә торган булган.

